ЧӘЧКӘЛӘР СЕРЕ

Ипи кибетендә дә, базарда да, юл чатында да чәчәк саталар

> 7

БЕЗНЕҢЧӘМЕ?

«Туган тел» клубының чираттагы утырышы интернетта татарча мохит темасына багышланды

> 16–17

ИЛСӨЯР ИКСАНОВА:

«Без милләтебезне, әти-әниебезне сайлап тумыйбыз»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 30 (29190) | Җомга | 8 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ru.freepik

ҖИРНЕҢ ФӘРЕШТӘСЕ

ЕЛНЫҢ ИҢ МАТУР КӨНЕН ТАГЫН ДА ЯМЬЛЕРӘК ИТҮЧЕЛӘР ТУРЫНДА

Шулай гадәтләнгән: 8 Март бәйрәме – безнең өчен иң элек әниләр бәйрәме ул. Беренче эш итеп якын, бердәнбер, кадерле кешеләребезне котларга ашыгабыз. Әниләр исән чакта, барыбыз да бала без. Әллә нинди югары вазыйфаларны биләгән түрә дә, зур сәхнәләр тоткан җырчы да, таң белән уяныш, җиһанга төн төшкәндә генә кырларыннан кайткан игенче дә, галимнәр укыткан мөгаллим дә...

> 6

МАТУРЛЫК ӨСТӘҮЧЕЛӘР

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле хатын-кызлар!

Сезне чын йөрәктән Халыкара хатын-кызлар көне белән тәбрик итәм!

8 Март – күңелдә җылы хисләр уята торган иң яраткан бәйрәмнәребезнең берсе.

Сез безне игелекле эшләргә рухландырасыз, яшәвебезгә яктылык, нур һәм матурлык өстисез. Дәүләтебез үсешенә саллы өлеш кертәсез, җәмгыять көнкүрешенең иң җаваплы юнәлешләрендә, беренче нәүбәттә мәгариф һәм фән, мәдәният һәм сәнгать, социаль яклау һәм медицина өлкәләрендә хезмәт куясыз.

Теләктәшлегегезне, ярдәмегезне һәрдаим тоя килеп, без бергәләп кыенлыкларны һәм сынауларны җиңә барабыз.

Сез – эчке сизгерлек һәм зирәклек белән гаилә учагын, ана сөте белән канга сеңгән рухи хәзинәләребезне, мәдәниятебезне һәм туган телебезне саклаучылар. Хатын-кызның гаять мөһим роле нәкъ менә шуннан гыйбарәт.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле еллары аша узган хатын-кыз ветераннарыбыз, махсус хәрби операциядә катнашучылар – кулына корал тотып, дәүләтебезнең бәйсезлеге өчен көрәшүче хәрбиләрнең әниләре, хатыннары иң ихлас рәхмәт сүзләренә һәм ихтирамга лаек. Ватанга хезмәт итү юлын сайлап, хәрби һәм хезмәт бурычын җиренә җиткереп үтәгән хатын-кызларыбыз белән без чиксез горурланабыз.

Ана һәм бала иминлеген яклауның, гаиләләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуның, гражданнар сәләт-мөмкинлекләрен тулысынча ача алсын өчен шартлар тудыруның әһәмиятен игътибар үзәгенә алып, 2024 ел Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин тарафыннан Гаилә елы дип игълан ителде. Илкүләм лидерыбыз әйткәнчә, бала тудыру һәм тәрбияләү – гаиләнең гаять әһәмиятле бурычы. Бу исә Россиянең күпмилләтле халкы үсеше, алгарышы нигезен тәшкил итә.

Кадерле хатын-кызлар!

8 Март – халкыбызның барлык буыннарын берләштерә торган зур тантана һәм сезнең шәфкатьлелек, мөлаемлык, чибәрлек һәм нәфислек кебек барлык күркәм сыйфатларыгызны тану, сезгә соклану хисләрен белдерү өчен күркәм форсат булып тора.

Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, күңел күтәренкелеге телим. Гаиләләрегездә татулык, муллык, бәрәкәт һәм мәхәббәт хакимлек итсен!

Районнарда ни хәлләр?

Саба

Сабада «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы кысасында тантаналы төстә яшь гаиләләргә торак сертификатлары тапшырылды. Районда берьюлы 10 гаиләнең торак сертификаты алганы юк иде әле. Беренче булып сертификат Хуҗиннар гаиләсенә бирелде. «Без сертификат алырга 4 бала белән килдек. Иң олысына – 11 яшь, кечесенә – яшь тә биш ай. Күпбалалы гаиләләргә бирелгән җиребез бар. Шул урында субсидиягә йорт салырга җыенабыз», – диде Илүсә Хуҗина.
(«Саба таңнары»)

Мамадыш

Югары Кыерлыда Булат Газизов, Мәскәүдән туган ягына кайтып, авыл хуҗалыгы кооперативы ачкан. «Авылга кайткач, атлар белән кызыксына башладым, 20 колын, аннан 25 татар токымлы ат алдым. Авыл халкы өчен бу сәер күренде, башта кырын гына карап йөрделәр. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ярдәме белән колыннар алып кайттык. Авылда яшәүчеләр, шул атларны үстереп, безгә сата алачак», – ди Булат. Фермерның теләге – авыл белән бергә эшләү. «Элеккеге мәктәп бинасын сатып алдык. Ат итеннән продукцияне шунда җитештерергә уйлыйбыз», – ди ул.
(«Татар-информ»)

Биектау

2022 елның ноябрендә Биектау районының Айбаш авылында 1855 елда төзелгән борынгы мәчетнең манарасы ауган иде. Хәзерге вакытта иман йортында төзекләндерү эшләре дәвам итә. Моның өчен 90 млн сум акча һәм кимендә ярты ел вакыт кирәк. «Озакламый мәчет ишекләре ачылыр, дип өметләнәм. Билгеле, эшләрне Республика көненә кадәр тәмамлыйсы иде, әмма өлгермәбез», – ди Татарстанның мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин. Реставрация ясаучылар борынгы гыйбадәтханәнең һәр бүрәнәсенә сак карый, саклап калынган һәр өлеш төзекләндерүдә кулланыла. Ә Айбаш авылы халкы өчен дин йорты булып вакытлыча мәчет янындагы җылытылган вагон хезмәт итә.
(«Биектау хәбәрләре»)

Түбән Кама

Түбән Камада 200 меңнән артык чәчәк утыртырга ниятлиләр. Хәзерге вакытта «Горзеленхоз» оешмасы язгы чәчәкләр утырту өчен үсентеләр әзерләүгә кереште. Чәчәкләрнең төрләренә килгәндә, алар – температура үзгәрешләренә иң чыдам булган петуния, сальвия, бегония, бәрхет чәчәк, газания, агератум, цинерария, колеус.
(«Татар life – Түбән Кама шәһәре»)

tatarstan.ru

Бүгенге катлаулы чорда хатын-кызлар – махсус хәрби операция зонасында ил иминлеген саклаучыларның ышанычлы терәге. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган тантаналы чарада шулай дип белдерде. «Бүген залда тормышның төрле өлкәләрендә уңышка ирешкән, фән һәм бизнес белән шөгыльләнүче, Ватаныбыз хакына хезмәт итүче гүзәл затлар утыра. Кайберләрегез үз гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган. Сезнең һәркайсыгыз үзенчә сокландыра. Фидакарь һәм мөлаем булуыгыз эчкерсез соклану, хөрмәт уята», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстанда – гүзәл затлар

Татарстанда 2,1 миллион хатын-кыз яши. Бу – республика халкының 53,3 проценты. Хатын-кызларның – 77,7 проценты шәһәрдә, 22,3 проценты авылда көн күрә. 43,2 проценты югары белемгә ия.

Эш урыннары

Сәүдә, ремонт, туклану һәм кунакханәләр	23,2%
Мәгариф	17,5%
Эшкәртү сәнәгате	12,6%
Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү	11%
Авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык	5,8%

Яшьләре



БУРЫЧ БИЛГЕЛЕ

Татарстан буенча эчке эшләр министры вазыйфасына яңа җитәкче билгеләнде. Хезмәт коллективына полиция генерал-майоры Дамир Садретдиновны тәкъдим итү чарасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм видеоэлемтә аша Россия Эчке эшләр министры, Россия полициясе генералы Владимир Колокольцев катнашты.

Татарстан Рәисе Дамир Садретдиновның яңа вазыйфада ведомство эшенең сыйфатын югары дәрәҗәдә саклап калачагына ышаныч белдерде.

– Соңгы елларда, күп очракта югары һөнәри осталык, хезмәт сөючәнлек, эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең фидакарьлеге нәтиҗәсендә, Татарстанда криминаль хәл тотрыклы, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Дамир Садретдинов 1994 елдан бирле эчке эшләр органнарында төрле вазыйфаларда, шул исәптән Әстерхан өлкәсендә, Хакасия Республикасында, Ханты-Манси автономияле округы – Юграда җитәкче булып хезмәт иткән.

Татарстан Рәисе министрлык шәхси составының соңгы ике атнада Казанда «Киләчәк уеннары» халыкара турнирын үткәргәндә иминлекне тәэмин итүен дә искәртте. Ул Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләренә намуслы эше һәм җаваплылыгы өчен рәхмәт белдерде.

– Сезнең эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре үзгәрешсез калды, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Ил Президентын сайлауга санаулы көннәр кала, һәм бу – бик җаваплы бурыч. Моннан тыш, сентябрьдә VII чакырылыш республика Дәүләт Советы депутатларын сайлау узачак. Сайлауларны югары оешкан дәрәҗәдә үткәрергә, аларның иминлеген тәэмин итәргә кирәк.

Быел Татарстанда халыкара дәрәҗәдәге чаралар да көтелә. Әйтик, октябрьдә Казанда БРИКС саммиты узачак, ә июньгә исә БРИКС уеннары билгеләнгән. «Мондый зур чараларны уңышлы үткәрү зур әзерлек эшен таләп итә», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Аның әйтүенчә, республика һәрвакыт министрлыкка финанс һәм матди-техник ярдәм күрсәтә. Соңгы елларда полициянең участок хезмәткәрләре өчен 179 административ-торак комплексы файдалануга тапшырылган, 129 участок полиция пункты һәм 194 тәртип саклау пункты эше тәэмин ителгән. Ведомство хезмәткәрләренә торак шартларын яхшырту, хезмәт транспорты белән тәэмин итү кебек юнәлешләрдә дә ярдәм итәләр. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгына караган күп кенә объектлар капиталь ремонт программасына керә. Шулай ук республика бюджеты хисабыннан яңа административ биналар төзелеше дә дәвам итә.

– Республика алга таба да хокук тәртибе органнарына нәтиҗәле хезмәте өчен шартлар тудыруда ярдәм итәчәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Без Артем Хохорин җитәкчелегендәге министрлык коллективы башкарган эшне һәм аның сыйфатын югары бәялибез.

Билгеле булганча, Артем Хохорин әлеге вазыйфада 12 ел эшләде.

ЕРАГАЙМАСЫН АРА

ТАТАР ЭШМӘКӘРЛӘРЕ КУКМАРА РАЙОНЫНА СӘФӘР КЫЛДЫ

Алсу Сәлахетдинова/ «Хезмәт даны»

Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены делегатлары Кукмара районы белән таныштылар. Алар, берничә төркемгә бүленеп, төрле авылларда булды. Без утырган автобус Зур Сәрдек, Купка, Аш-Буҗи авылларына тукталды. Сәфәр бик күңелле узды: юл буе безне җыр һәм кояш озата барды.

Иң элек кунаклар Зур Сәрдек авыл клубы һәм гимназиясе белән таныштылар. Башка мәктәпләр, укучылар кими, авылда яшьләр калмый, дисәләр, биредә узган ел беренче сыйныфка 35 бала укырга кергән. Барлык филиаллардан 45 бала бишенчегә килгән.

– Татар авылларында эшләүче гимназияләр күп түгел. Бүген мәктәптә 319 бала укый, 47 укытучы эшли. Укыту саф татарча алып барыла. Бүтән милләттән булган бер генә балабыз да юк. Шуңа күрә мәктәбебездә татар мохитен саклап яшәү бер дә кыен түгел. Кызганыч, һәркемгә хас проблемалар бездә дә бар: мәктәп бетергән балаларның кире авылга кайтмаулары, башлангыч сыйныфта укыганда ук кулларына телефон тоткан балаларның русча сөйләшергә омтылулары. Ләкин без барлык мөмкинлекләрне файдаланып (ә алар бездә күп), укучыларны төрле яклап кызыксындырабыз, – диде директор урынбасары Гөлсинә Зыятдинова.

Кукмара районының тырыш, булдыклы эшмәкәре Фәнис Хәмәтдинов турында күпләр ишетеп белә. Бу көнне исә делегатларга аның үзе һәм эшчәнлеге белән танышу бәхете дә тәтеде. Кунакларны башта Аш-Бужи авылындагы ипи, кондитер ризыклары әзерләүче «Адай икмәге» цехына алып керделәр, шуннан соң Купкадагы «Кукмара сөте»нә алып бардылар.

– Пекарнядан көн саен – 700 мең сумлык, сөт комбинатыннан 300 мең сумлык продукция чыга. Алда торган бурычыбыз – пекарняныкын – 1 миллион, комбинатныкын 500 мең сумга күтәрү. Ризыкларыбыз унөч районның 500 кибетенә таратыла. Болардан тыш, узган ел чеби үстерү эшен дә башлап җибәрдек. Бер айлык 26 мең бройлер чебие саттык. Быел 56 мең чеби өчен акчаны күчереп куйдык. Киләчәктә ярымфабрикатлар эшләү нияте дә бар. Моннан тыш, без әле 780 кешене «Әмирхан» кооперативына да берләштереп торабыз, – дип, эшчәнлеге белән таныштырды Фәнис Хәмәтдинов.

Сөтне исә фермерлардан җыялар.

– Без сөтне күрше-тирә авыллардагы ышанычлы фермерлардан гына җыябыз. Аларның сөте чыннан да бик сыйфатлы. Литрына 29 сум түлибез. Бик тәҗрибәле технологыбыз эшли, бу эштә шундый шәп белгечең булса, беркем дә кирәкми, – диде ул. – Бүген эшмәкәрләр кадрларга кытлык кичерә, тик бездә әлегә андый проблема юк. Аларның уртача хезмәт хакы – 45 мең сум. Эшчеләр 35 мең сумнан 85 мең сумга кадәр хезмәт хакы ала. Комбинатта рентабельлек – 14, пекарняда 18 процентны тәшкил итә. Өч ел дәвамында берничә кредитсыз эшлибез.

Аның эш алымнары күпләрдә кызыксыну уятты. Башка төбәкләрдән килүчеләр эшчеләренең хезмәт хаклары, эшләү шартлары, чыгымнарына бәйле сорауларга күмде.

Ульян эшмәкәре Фәнис Җәббаровның Кукмара районына беренче генә тапкыр килүе түгел икән. Моннан ун ел элек тә булган. Шул вакыттан бирле шактый үзгәрешләр булганлыгын әйтте.

– Район тагын да «киңәйгән», «тирәнәйгән». Сокландым, тик гаҗәпләнмәдек, чөнки хәзер кешеләрне гаҗәпләндерү бик авыр бит, – диде ул. – Без дә бөтенләй үк артта калганнардан түгел, ләкин барыбер күп нәрсәләрдә Татарстаннан үрнәк алабыз. Безнең егетләребезнең һәркайсы булдыклы, яңа технологияләр кулланып эшләсә дә, өстәмә белем алу беркемгә дә комачаулык итми. Шуңа күрә җыен безне берләштерүе, таныштыруы белән кадерле. Моннан танышып кайткан кешеләр белән хезмәттәшлекне һәрвакыт дәвам иттерәбез.

Сәфәр Кукмара районының мәдәният йортында тәмамланды. Маршрут нокталары күп булмаганлыктан, күңелгә: «Килгән кунаклар Кукмараның чын йөзен күрми китә инде», – дигән шик тә кереп оялаган иде. Тик кукмаралылар сыната торганнарданмыни соң инде?! Мәдәният йортында иң төп брендларыннан торган күргәзмә оештырганнарын күргәч, күңелгә җылы керде. Теләге һәм кесә янчыгы калын булганнар Кукмарадан истәлеккә савыт-саба, киез итекләр, милли бизәкле оеклар һәм футболкалар, өс киемнәре, борай ярмасы, тәм-томнар алып китте.

Делегатлар пленар утырышта катнашты һәм концерт карады. Аларны район башлыгы Сергей Димитриев сәламләп:

– Районыбыз үссен, алга барсын өчен тырышабыз. Төрле программаларда катнашабыз. Районга кадак кайтса да – файда, дибез. Бездә күргәнне үзегездә куллансагыз, нәтиҗә булыр. Киләчәктә дә очрашырга насыйп булсын, – диде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Язучы сүзе

Бүләккә тәкъдим итү

Моңа охшаш хәлләр еш очрап тора, шуңа җирлеген дә, исем-атларын да күрсәтеп тормыйм. Мәсьәлә гади генә инде. Авылда бер гаилә биш бала табып үстерә икән, шуның өстенә болар тагын тугыз баланы тәрбиягә алганнар. Бер танышлары киңәше белән бу ханымны Татарстанда бирелә торган «Ана даны» медаленә тәкъдим итәргә булалар. Документлар туплый башлыйлар хәзер. Авыл хакимиятеннән дә характеристика кирәк икән. Бик озак көттермичә генә авыл хакимияте язып бирә. Язманың беренче җөмләсе… Хәер, икенчесе дә… Мактарга тырышып язганнар бугай инде аны. Әмма хакимият башлыгы мактау сүзләренә саран кеше булганмы, характеристикасы бик кызык килеп чыккан. Аз гына пародия рәвешенә кертеп, шуны сезгә дә тәкъдим итәм әле. Укыгыз, сез дә сөенегез. Авылыгыздагы мактаулы шәхесләрне хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итәргә кирәккәндә, шундыйрак характеристикалар язып бирерсез.

«Фәләнова Флүрә Фәлән районның Түгән авылындагы үз өендә үз ире белән яши. Пенсионер. Ире Фәләнов Фәлән үзенең автосервисында эшли.

Флүрә аракы эчми, самогон кумый, хәтта сырага да якын килми. Авыл кибетеннән «Трояр», «Ясон», «Нитхинол» һәм башка суррогатлар сатып алганын күрүче булмаган. Үзе дә хәмер сату белән шөгыльләнми. Тәмәке тартмый, махорка үстерми, электрон сигарет суырып йөрми. Беркайчан да азгынлык юлында тотылганы юк. Күкрәгенә дә, аркасына да, хәтта беләгенә дә наколка ясатылмаган. Шул килеш тә озын җиңле озын күлмәк киеп, чәчен-башын каплап йөри. Пирсинг такмый. Мәчеткә йөри, намаз укый.

Үз балаларының барысы да бер атадан. Барысы да үз әтиләренә охшаган. Калган тугызы – тугыз әтидән. Балалары һәрвакыт чиста киемнән йөри, урамда да, мәктәптә дә, башка урыннарда да авылдашларыннан акча яки ашарга сораганнары юк. Яхшы укыйлар, бер сыйныфта икешер ел утырып калганнары юк. Тәртипләре дә әйбәт – урамда очраганда исәнләшеп үтәләр.

Тормыш иптәше – бик абруйлы кеше. Күп эчми. Исерми, исерсә дә, килде-китте сөйләнеп йөрми. Үз хатынын кыйнамый. Бүтәннәрнекен дә. Гомумән, бик итагатьле кеше. Балаларына бер авыр сүз дә әйтми. Хәтта унтугызга җиткән өлкән кызын да берсүзсез кияүгә бирде…»

Алдан әйткәнемчә, буяуларны чүт кенә куертыбрак сурәтләгәндә, теге хакимият башлыгы язган характеристика шушылайрак килеп чыга. Медальгә тәкъдим ителүче авылдашына бу. Аналык хокукыннан мәхрүм ителергә торган хатынга түгел.

Югыйсә язарлык сүз тапмый аптырап торырлык кешеләр дә түгел икән болар, җәмәгать эшләрендә, авыл тормышында бик актив катнаша торган гаилә икән. Үзешчән сәнгать белән шөгыльләнәләр, төрле бәйрәмнәр оештырганда башлап йөриләр. Балаларының кайсы биюче, кайсы җырчы, кайсы музыка коралларында уйный икән. Үзешчән сәнгать белән бергә спорт ярышларында да беренчелекне яулыйлар. Район данын яклау гына түгел, республика күләмендәге бәйгеләрдә дә җиңү алып кайталар. Һәртөрле олимпиадаларда җиңәләр. Уйлап чыгарасы да юк бит инде, бер карасаң, яз барысын да ничек бар – шулай итеп. Ачуым да бер килмәгәе, үзең юллап алып бирерлек бит инде медаль-фәләнне авылыңның шундый кешеләренә.

Юк. Монда нәкъ менә: «Фәлән Фәләнова аракы эчми, тәмәке тартмый», – дип язарга кирәк. Әйтерсең, ундүрт бала карап үстергән хатынның иң зур өстенлеге фәкать шул гына – эчмәү, тартмау, уйнаш итмәү.

Бу хакимияттәге әфәнде һәм ханымнарның наданлыгыннан да, рухи фәкыйрьлегеннән дә киләдер инде. Күремсезлек дигән нәрсә дә үзен сиздерәдер. Шуңа ияреп тәкәбберлек, башкаларга өстән карау, җавапсызлык кебек сыйфатлар да баш калкытадыр. Нишлисең инде… Шулай да үз мескенлеген күргәзмәгә куя берәүгә дә килешми бугай. Хәтта хакимчекләргә дә.

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Паника

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Махсус хәрби операция уңаеннан халык арасында кайбер чыш-пышлар башланды. Ачыктан-ачык мәгълүмати сугыш барганда, кайберәүләр нигәдер, Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, дошман тегермәненә су коя. Янәсе, безнең матбугатта чыккан язмалар, телеэкраннардагы видеосюжетлар дөреслеккә туры килми, алар чепчи ялган.

Фикерләр сугышы гасырлар буе олы орышларның аерылмас бер өлеше булып килгән. Ни өчен? Паника куптару, ягъни коткы тарату кешене куркуга сала, ул акылын, кешечә фикерләү сәләтен югалта. Курку хисе аерым бер кешенең генә түгел, зурзур төркемнәрнең акылын биләп алырга мөмкин. Психологлар моны бәндә баласында «котү булып яшәү» инстинкты барлыгы белән аңлата һәм бу хис, күрәсең, мәңгелек. Миңа «цензура» һәм «паника» дигән сүзләр бер үк вакытта, һич югы бер-бер артлы туган кебек.

Заманында цензура тарихын бераз өйрәнгән идем. Әле безнең эрага хәтле фәләненче мең елларда ук төрле халыклар үзара оешып дәүләтләр барлыкка китерә башлый. Дәүләт булгач, идарә дә кирәк бит инде. Дәүләт идарәсе оешуга «дәүләт сере» дигән төшенчә дә барлыкка килмәде микән? Бүген без яратып әйтә торган «өйдәге чүпне тышка чыгармау» дигән сүзләр әнә шул ерак гасырларга барып тоташмагае. Авызын әйткәнне колагың ишетү кирәклеге законнар белән ныгытыла килгән. Җәмгыятьтә килеп туган вазгыятькә карап, цензура да урнаштырылган.

Тарихчылар язуынча, цензурага безнең эрага хәтле IV гасырларда яшәгән фәйләсуф Платон нигез салган. Балаларны начар мәгълүматтан араларга кирәклеге турында язып калдырган ул, без балаларның төрле уйдырмалар, теләсә кем авызыннан чыккан каршылыклы фикерләр тыңлап үсүенә юл куймаска тиеш, дигән. Ул заман цензурасы кешенең бөтен гамәлләрен, «мал-мөлкәт»ләрен исәпкә алудан башлап, халыкта югары әхлак ни дәрәҗәдә икәненә хәтле ныклы күзәтү астына алган.

Мин тарихка махсус тукталдым. Укучым цензура, ягъни төрле тыюларның, чикләүләрнең кешелек җәмгыятенә ни өчен кирәк булганлыгы турында үзе дә уйлансын, дидем.

Язмамны «Паника» дип атау да очраклы түгел. Чөнки дөньялар болганган, җәмгыять зур үзгәрешләр кичергәндә, бу сүзнең мәгънәсе тагын да аныклана кебек. Бөек Ватан сугышы елларында теләсә ни сөйләп коткы таратып йөрүчеләрне фашистларның шпионына тиңләгәннәр. Паникерларны судсыз-нисез атып үтергәннәр. Андый законнар кайтмас, әлбәттә. Әмма бүген халык дөньяның тынычлануын көтеп, газизләрен югалткан ата-аналар кайгыга батып яшәгәндә, килде-китте сүзләр сөйләп йөрүдән кемгә нинди файда соң? Безнең татар: «Кирәксез сүзне дөрес булса да сөйләмә», – ди. Бу «Авызыңа май кап, тының да чыкмасын!» дигән сүз түгел. Халык сүзнең башыннан элек төбен уйларга өйрәнгән. Бу – тормыш, язмыш сабагы.

Миңа махсус операциядә катнашканнар белән дә, һәлак булган егетләрнең ата-аналары белән дә очрашырга туры килде. Күзләре яшьле, йөрәкләренә кан сауган булса да, сер бирмәскә тырышты алар. Алай гына да түгел, аналар, мәсәлән, улларының нинди батырлык күрсәтүләрен күбрәк белергә тели, аларның данын яшәтәсе, гомерлек итәсе килә иде. Яу кырындагы хәлләр турында теләсә ни сөйләп, үлгәннәрнең рухын рәнҗетмибезме без?!

Мин бүген паникерларны исемләп атарга җыенмыйм, исемнәре дә, үзләре дә кирәк түгел. Намусларына көч килмәсме, дип кенә әйтүем.

ХАТЫННАР БАТЫРЛЫГЫН БӘЯЛӘГӘНДӘ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Бу атнаның дүшәмбесендә АКШның Дәүләт департаментында Хатын-кыз батырлыгы өчен халыкара премия бирү тантанасы булып узды. Премия 2007 елда бирелә башлаган һәм аны инде 90 илдән 190нан артык хатын-кыз алган. Лауреатларның күбесенчә мөселманнар яшәгән илләрдән булуы американнар аңлавындагы хатын-кыз батырлыгының либераль карашларга бәйле булуын аңларга ярдәм итә.

Тик менә аларның нинди батырлык эшләүләре генә мәгълүм түгел. Бары тик япон хатыны Рина Гоноиның гына харрасментка – ирләрнең җенси бәйләнүләренә каршы баш күтәреп дан яулаганы билгеле. Гоноi Япониянең коры җир гаскәрләрендә хезмәт иткән, әмма ирләрнең бертуктаусыз үзенә кул белән кагылулары, бәйләнүләренә түзә алмыйча протест белдереп, армиядән киткән, япон хөкүмәтеннән компенсация таләп иткән. Яклау тапмагач, интернетта зур шау-шу кубарган, тагын армия сафларында булган йөз иллеләп хатын-кыз үзләренең дә шулай ук рәнҗетелүләрен әйтеп, аны яклап чыккан. Шуннан соң гына япон рәсми даирәләре эшне зурга җибәреп, тикшерү эшләре башлаган.

Хатын-кызны армиягә алсаң һәм ирләр белән бер сафта хезмәт итәргә мәҗбүр итсәң, көчле җенеснең кул озайтуы гаҗәп түгел. Либераль идеология хакимлек иткән дәүләтләрнең барысында да (һәм, гомумән, ирләр белән хатыннарның тыгыз аралашып эшләүләренә юл куйган барлык илләрдә дә) харрасмент киң таралган. Бик кызык вазгыять инде бу: хатыннарны ирләрдән аерып куйсаң, бу аларның хокукларын бозу булып санала, янәшә эшләү мөмкинлеге бирсәң, кул белән кагылып китү һәм тагын да тирәнрәк мөнәсәбәтләр котылгысыз. Гадәттә хатын-кызлар үзләре дә аңа бик каршы түгел, бары тик шул вазгыятьтә зур акча эшләү мөмкинлеге туганда гына көрәшчеләр сафына басалар.

Атаклы француз актеры Жерар Депардье бар бит әле. Менә шул Депардьеның харрасментта гаепләнүләрдән башы чыкмый. Матбугатта үзенең кул озынайтуларын кире каккан мөрәҗәгатьләр дә бастырып карый. Ләкин Депардьега кем ышансын, аның кем икәне йөзенә үк чыккан. Әле күптән түгел генә француз актрисасы Элен Даррас комсыз актерның 2007 елда үзенең интим җирләренә кулы белән кагылуын искә төшерде. Күрәсең, теге чакта Даррас акчага алай ук мохтаҗ булмагандыр, хәзер исенә төшкән. Әмма француз тикшерүчеләре күп вакыт үтүен искә алып, эшне ябарга да мөмкин икән. АКШ Дәүләт департаментының премиясен алуга да өмет аз, чөнки ирләр кочагында булып чыккан барлык көнбатышлы хатын-кызларга да премия өләшә башласаң, Америка казнасында акча җитмәячәк.

Әнә Трампны дистәләгән хатын-кыз кул озайтуда гаепли. Рейчел Крукс дигән ханым, мәсәлән, 2016 елда ук, аны гаепләп, «Нью-Йорк Таймс» газетасына хат юллап караган – игътибар итмәгәннәр. Яңа сайлау алды көрәшендә Крукс шулай ук тагын бер талпынып карый, гомуми шаукым барышында олигархтан акча савып булмасмы дип өметләнә. Трамп исә социаль челтәрдә «үзе кадәр беркемнең дә хатын-кызны хөрмәт иткәне юк»лыгын әйтеп аклана. Трампның «тәкъвалыгы» йөзенә чыккан, ул шундый кәҗә: янына кәбестә куй, борылып та карамый. Шуңа карамастан Американың телеолдызлары, атаклы журналистлары, модельләре булган ханымнар аңа бәйләнүдән туктамый. Дәүләт департаментына эш җитәрлек инде монда, интим урыннарын көрәш коралы итеп батырлык эшләргә чиратка баскан хатыннар

американнарның үзләрендә дә санап бетергесез. Ләкин бу ил чиновниклары башка илләрдәге хатыннар хокукы өчен борчылып төн йоклый алмый. Фәләстыйнда үтерелгән әниләр һәм балалар канына аларның бик исе китми, сиончыларны үтерү кораллары белән мул тәэмин итүләрен туктатмыйлар. Берәр хатын башыннан яулыгын салып, батырлык эшләсә, сәяси көрәшнең киң кыры ачыла.

Эпштейн утравына коллыкка сатып алып китерелгән меңнәрчә хатын-кызның һәм балаларның элекке Америка Президентлары, сәяси элиталары, олигархлары тарафыннан күп еллар буе көчләнеп биктә тотылуы турындагы зур җинаять эше дә шаулап кына алды да бик тиз тынды. Шуңа охшаган башка күп җинаятьләрнең дә тавышы чыга башлауга очларын яшерделәр. Күрәсең, коллыкка төшкән меңләгән хатын-кыз арасында халыкара премиягә лаек булырлык батырлык эшләүче табылмаган.

Хатын-кызның хәлен, аның хокукларын яклау һәм бәяләүне Америка администрациясенә тапшырсаң, нәтиҗәләре бик гаҗәп һәм кызыклы килеп чыгачак. Болар бит чынлыкта хатыннар-ирләр юк дип саный яисә, кешеләр ике генә җенестән тормый, дип әйтергә дә күп сорамыйлар. Әле күптән түгел генә Байден администрациясе «гендер тикшеренүләр өчен» миллион доллар акча бүлеп бирде. Башында Байден торган югары чиновниклар армиясе Аллаһ тарафыннан «ирләр һәм хатыннар гына түгел, башка бик күп төрле җенесләр дә бар ителде» дип саный. Күзгә күренмәгән шул җенесләрне табып, «тагын да инклюзиврак булган» биология дәреслекләренә кертү һәм табигать белемнәре буенча белгечлек алучы студентлар кулына тоттыру максат ителде. Байденның 2021 елның июлендә имзалаган 14075 номерлы указы бар. Ул указ трансгендерларны яклауны күз алдында тота. Бер Америкада гына түгел, бөтендөньяда шул эшчәнлектә эш җәелдерергә әмер биргән. Көнбатыш либераль фикере хәзер туганда баланың җенесен ачыклау түгел, үсә төшкәч, пропаганда тәэсиренә бирелеп, үзен кем дип атасы, шул җенестә дигән идеяне алга сөрә. Французларның яңа премьеры Габриэль Атталь бар бит әле. Ничек уйлыйсыз, ул ир кешеме, әллә хатын-кызмы? Болай тышкы билгеләре буенча ир кеше инде, әмма, гафу итегез, кияүгә чыкты. Йортка кергән дип аңламагыз тагын, ул чын-чынлап ир кеше белән үзен хатын-кыз ролендә тәкъдим итеп, гаилә корды. Премьер булганчы, ул мәгариф министры иде. Франция мәгарифендәге хәлләрне шуннан чыгып күз алдына китерә аласыз. Үткән елның августында Атталь Франциянең уку йортларында традицион хатын-кыз киемен тыйды. «Мөселманнар хокуклары өчен хәрәкәт» ассоциациясе моңа каршы чыгып карады, уңышка ирешә алмады. Шуңа күрә Байден администрациясе киләчәктә Аттальгә Хатын-кыз батырлыгы өчен халыкара премия тапшырса, бер дә гаҗәпләнмәгез.

Сәрия МИФТАХОВА

МАКСАТЫ БАР, ТЕЛӘГЕ ЮК?!

МАКСАТЧАН ПРОГРАММА БУЕНЧА УКУ: АКЧА ҖИЛГӘ ОЧМАСЫН

Диплом алгач, кире кайтасы! Максатчан программа (целевое обучение) буенча укырга керүчеләрне кат-кат кисәтәләр. Тик яшь белгечләр вәгъдәләрендә торамы соң? Килешүне бозган өчен күпме штраф түлисе? «ВТ» хәбәрчесе максатчан программаның өстенлекле һәм тискәре якларын белеште.

Максатчан укыту төрле тармакларда кадрлар кытлыгын хәл итүне, предприятие, дәүләт органнары ихтыяҗларына туры килерлек белгеч әзерләүне күздә тота. Аның өстенлеге: бушлай уку, вузны тәмамлагач, гарантияләнгән эш урыны, укырга кергәндә махсус конкурс һәм социаль ярдәм.

Россия Хөкүмәте квоталарны барлык бюджет урыннарыннан чыгып билгели. Вузлар аны 10 апрельдән соңга калмыйча сайтларында урнаштырырга тиеш.

Хәзерге вакытта мондый урыннар бигрәк тә авиация, ракета двигательләрен проектлау, тимер юл, күпер төзүчеләргә күбрәк биреләчәк. Шулай ук илгә табиб, мәдәният хезмәткәрләре дә җитми. Алар да максатчан программага кертелә. Моңа кадәр фундаменталь һәм гамәли биология, наноинженерия, наноматериаллар юнәлешләрендә «целевик»лар әзерләнмәсә, хәзер аларга да игътибар артачак.

Хата

Гүзәл Гатауллина вузда дүрт ел буе максатчан программа буенча укыган, әмма бүген эшләми. Укыган өчен тотылган акчаны кайтармаган, аны берәү дә эзләп йөрми.

– Һөнәремне әни киңәше белән сайладым. Ул юрист булуымны теләде. Ә минем артист буласым килгән иде. Максатчан юнәлеш буенча дүрт ел укыгач, укырга җибәргән оешмада берничә ай эшләдем дә киттем. Эшем шәһәрдә иде югыйсә, тик кечкенә хезмәт хакына интегеп йөрисем килмәде. Бәхетем бар: оешма җитәкчесе таләпләр куймады. Хәзерге вакытта фотога төшереп, маникюр ясап, заманча сумкалар тегеп акча эшлим, – ди 23 яшьлек Гүзәл.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ә менә Гапсәләмовларга кыенрак булган. Кызлары бер ел укыган өчен, 157 мең сум акчаны кире кайтарганнар.

– Кызыбыз Казан дәүләт ветеринария медицинасы институтында «целевик» иде. Бер елдан соң укуын ташлады. Югыйсә мал табибы булу хыялы иде. «Бу – минем өлкә түгел», – диде. Хәзер психологка укый, – ди Лаеш районында яшәүче Диләрә Гапсәләмова. – Әле ярый кызыбыз вакытында хәл итте. Диплом алгач, эшкә кайтмаса, нишләр идек? Ул укырга кергәндәге шарты буенча Теләче районындагы оешмага кайтып, өч ел эшләргә тиеш иде. Әле аны табу да җиңел булмады.

Саба районының Миңгәр авылы кызы Ильмира Исхакова КФУда укытучылыкка укый. Тагын бер елдан диплом алып, Шәмәрдән мәктәбенә кайтып, биш ел укытасы бар аның.

– Хәзер яшьләрнең күбесенең шәһәрдә каласы килә. Ә мин, киресенчә, авылга кайту яклы. Шуңа да максатчан укуны кулайрак күрәм. Беренчедән, эш урыны булачак. Икенчедән, авылларда укытучылар кытлыгын киметергә өлешеңне кертәсең. Авылга да ярдәм, чөнки яшьләр – авылның тоткасы, – ди Ильмира Исхакова.

Вазгыять

Татарстанда узган ел вузларда максатчан укыту юнәлешләренә 3447 урын бүлеп бирелгән. Быелгы квота апрельдә билгеле булачак.

– 747 студент күптелле һәм ике телле мәктәпләр программасы буенча белем ала. Рәисебез тарафыннан аларга ай саен 15 мең сум стипендия түләнә. Мәктәпкә килеп эшләү өчен күп энергия, белем һәм сабырлык кирәк. Әгәр дә әти-әниләр, җәмгыять укытучыга карата карашын үзгәртмәсә, алар мәктәпкә килмәячәк. Һәр сыйныфта – 25 бала, һәркайсының – үз холкы. Укучыларны сүгәргә дә ярамый, әмма шелтә белдермичә дә булмый, – ди мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин.

Максатчан программа буенча укучыларның күбесе үз районнарына кайта, берничә проценты гына кайтмаска мөмкин, ди министр. Ә менә укырга кереп, беренче курстан соң баш тарткан очраклар бар.

Мамадыш районы мәгариф идарәсе методисты Раилә Әхмәтшина әйтүенчә, алар арасында медицина, мәгариф, юридик, аграр, энергетика һәм башка юнәлешләр буенча максатчан укучы 100дән артык студент исәпләнә.

– Мәктәпләргә, максатчан юнәлешләрдә укырга теләүчеләр бармы, дип запрос җибәрәбез. Укучылар белән очрашабыз, җаваплылыкны аңлатабыз. Алар риза булганда, кадрларга ихтыяҗы булган оешмаларны эзлибез, – дип сөйли методист. – Укучыларның күбесе эшкә кайта. Педагоглар белән генә кайчак проблема туа. Алар практика үткән мәктәпләрендә кала. Укытучыларны Казан белән Чаллы шәһәрләре үзенә «йотып» бара.

Әтнә районының мәгариф белгече Лилия Габидуллина белдергәнчә, районда укытучылыкка 9 «целевик» укый.

– Хәзерге вакытта математика, җәмгыять белеме укытучылары кирәк. Гадәттә «целевик»лар үз мәктәпләренә кайта. Әгәр урын булмаса, башкасына күчерәбез, – ди Лилия Габидуллина.

Кадрлар

Казандагы «НИИтурбокомпрессор», «Казанькомпрессормаш» оешмалары кадрларны укытырга, аларга ярдәм итәргә тырыша. Профориентация, максатчан уку буенча Казан илкүләм тикшеренүләр технологик университеты (КХТИ), Казан илкүләм тикшеренүләр техник университеты (КАИ), Казан дәүләт энергетика университеты белән эшлиләр. Эшчеләр үзләре яки балалары укырга тели икән.

– Безнең оешмадагы барлык «целевик»лар да кире кайта. Алар килешүләрне Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аша төзи. Килешүне бозган очракта, штрафлар каралган, – ди «НИИтурбокомпрессор» оешмасының гыйльми сәркатибе Илмир Хәбибуллин.

Ниләр үзгәрә?

Быелгы яңалык – «Россиядә эш» порталында эш бирүчеләрнең бердәм базасына целевиклар әзерләүгә кагылышлы мәгълүматлар урнаштырачаклар. Моңа кадәр укучыларга эш бирүчеләрне үзләренә эзләргә туры килгән.

Кабул итү тәртибендә дә үзгәрешләр бар. Абитуриентлар документларын бары бер вузга һәм бер генә программага тапшыра ала. Моңа кадәр бишәр гариза бирү мөмкин булган. Хәзер оешма җитәкчесе килешүдә студентка нинди ярдәм тәкъдим ителәчәген һәм эш шартларын төгәл күрсәтергә тиеш. Студентның җаваплылыгы да арта. Мәсәлән, предприятие җитәкчесе студентның укуына карата таләпләр куя, начар укыганда килешүне өзә ала.

МАКСАТЧАН ПРОГРАММА БУЕНЧА УКЫРГА ТЕЛӘҮЧЕЛӘР ӨЧЕН

ЗАКАЗЧЫНЫ КАЯН ТАБАРГА?

Уку өчен түләргә әзер булган заказчыны табарга кирәк. Ул дәүләт корпорацияләре, министрлык, шәхси компанияләр, дәүләт оешмалары: хастаханә, театр, музей, булырга мөмкин. Абитуриент заказ бирүче белән килешү төзергә тиеш.

ҖАВАПЛЫЛЫК

✓ Заказ бирүче студентка укыганда стипендия түләргә, транспорт, яшәү чыгымнарын хәл итәргә булышырга, килешү буенча эшкә урнаштырырга тиеш.
✓ Студентның бурычы – яхшы уку, диплом алгач, эш урынында өч ел эшләү.

ЭШКӘ УРНАШТЫРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ БОЗЫЛСА

✓Заказчы «целевик»ка уртача өч хезмәт хакы күләмендә компенсация түли.
✓Максатчан укыган студент эш бирүчегә белем алуга киткән чыгымнарны кире кайтара.
✓Эшкә урнашу буенча бурычын үтәмәүче як вузга федераль, төбәк яки җирле бюджеттан студентны укытуга киткән чыгымнар күләмендә штраф түли.

ҖИРНЕҢ ФӘРЕШТӘСЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бөркетләр

Илшат, Илһам, Хәлил, Булат, Ислам... Әлмәт районының Кичүчат авылында яшәүче Фәридә Котбиеваның алтын бөртекләре – бөркет кебек улларының исемнәре бу. Бер бала да – җаваплылык, бер баланы кеше итәр өчен дә күпме көч, тәрбия, хезмәт кирәк! Улларыны кеше итеп үстерүнең сере дә – хезмәт тәрбиясе.

Ире Камил абый белән 1986 елда гаилә кора алар. Ул – механик, Фәридә апа исә – хәзер Ризаэддин Фәхретдин музеенда фондлар буенча хезмәткәр.

Бәхеткә булгандыр! Улларының рәхәтен, игелеген күреп яши хәзер Котбиевлар.

– Улларым дүртесе дә армиядә хезмәт итте. Хәзер төпчеге Ватан алдындагы бурычын үти, – ди әңгәмәдәшебез. – Улларыбыз тормышта үз урыннарын тапты. Олы улым Әлмәт башлыгы ярдәмчесе, тагын берсе – Әлмәттә балалар һәм яшьләр эшләре идарәсендә урынбасар, тагын берсе телефоннар ремонтлый, бер улыбыз – электрик. Кайда эшләсәләр дә, яратып башкарсыннар. Шулай булганда гына нәтиҗәсе була, күңел үсә.

Фәридә апа гаиләсе турында тыйнак кына сөйли. Аерылып торган бер нәрсәбез дә юк, янәсе. Әмма читтән яхшырак күренә бит...

– Өйдә начар сүз, сүгенү ишетмәделәр, «шулай бул» дип аерым аңлатып үстерү дә булмады. Аталары – бик тәртипле, тыйнак кеше. Гаиләдә иремне, аталарын авторитет итеп куйдым. Һәрвакыт! «Әтиегезгә әйтәм» дигән сүз җитә иде аларга. «Малай, ник тыңламыйсың?» – дип бер генә карый иде. Хәзер инде «малай» түгел, «улым», ди. Безнең өйдә аш булмасында әтиебезнең үз урыны бар. Аңа һәркемнең утырасы килә. Оныклар бабалары өйдә юкта менеп утыра инде *(көлә)*. Без үскәндә дә шулай иде. Мондый гадәтләр бик кирәк. Ата янында олы бала утырырга тиеш. Бу бик дөрес. Эш белән тәрбияләдек балаларны. Мал-туар күп иде. Бакчада барысын да үстердек. Кызлар булмагач, хатын-кыз эшен дә башкара иделәр. Алар әле хәзер дә кайбер эшләрне миннән яхшырак эшли. Балачактан калган шундый тәртип инде – һәркайсы үз эшен белә. Шөкер, киленнәребез, оныкларыбыз да бар. Кызлар сөяргә насыйп булды! Мин киленнәремне, кода-кодагыйларны хөрмәт итәм. Барысын да киңәшләшеп эшлибез. Атна саен кайталар, өй гөрләп тора, шөкер!

Сәхнәдә – актриса...

...ә өйдә – әни ул! Татарстанның атказанган артисты, курчак кебек кенә Альбина Гайзуллинаны ике бала анасы (баһадирдай икәү!) дип кем әйтер икән?

– Мин кырыс, таләпчән әни түгел. Ир балалар тәрбияләсәм дә, бик йомшак мин. Бәләкәй чакта да елатмыйча гына үстерергә тырыштым, аз гына тавышлары чыкса да, кулга ала идем. Хәзер дә иркәләп кенә үстерәм, – ди әңгәмәдәшебез. – Әмма алар иркә булып үсмәде. Чын ир-егетләр! Чөнки минем йомшаклык янында әтиләренең таләпчәнлеге булды. Гаиләдә әти сүзе бар.

ru.freepik

Ир-егетләр тәрбияләгәндә нинди кагыйдәләрне истә тоткан икән Гайзуллиннар?

– Иң беренче чиратта, хатын-кызга хөрмәт. Бу хакта гел әйтеп торам. Йорт мәшәкатьләре – хатын-кыз эше генә түгел. Аны бергә-бергә эшләгәндә генә рәхәт һәм күңелле. Дәү әти, дәү әниләргә, туган илгә, укытучыларга, кешеләргә хөрмәт тәрбияләргә тырышабыз.

Икенче кагыйдә – туганлык хисен саклау. Канга батып сугышсагыз да, бер-берегезне какмагыз, бер-берегезгә тартылыгыз, дип тукып торабыз. Минем энемнең балалары белән дә бик дуслар алар, шөкер. «Абый», «энем», «сеңлем» сүзләрен генә кулланып, исемнәре белән эндәштертмичә үстердек. Өченче кагыйдә – тәртип, өйдә татарча сөйләшү, – дип сөйләде Альбина Гайзуллина.

Тәрбия җимеше үзенекен итә бугай. Һәрхәлдә, әңгәмәдәш сөйләгәннәрдән шуны чамалап була:

– Хәзер үземә дә вакыт кала, һәрхәлдә, калдырырга тырышам. Инде балалар үсте. Өйдәге мәшәкатьләрне үз өсләренә алалар. Мәчене ашаталар, савыт-саба юалар. Мәктәптән кайткач, формаларын эләләр, идәннәрне дә сөртәләр. Соңгы бер-ике елда шулай. Аңа кадәр авыррак иде, билгеле. Хәзер эштән кайтып, ял итәргә дә вакытым бар, хәтта китап укырга да *(көлә)*! – ди Альбина Гайзуллина.

Бәхетле әни

– Үзебез дә гаиләдә өчәү үскәч, гаиләдә өч бала булырга тиеш дип уйлый идем. Аллаһка шөкер, мин – биш бала әнисе! – ди Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылында гомер итүче Алсу Мөхәммәтҗанова.

Тормыш иптәше Фәйзенур абый белән яшь аермасы – 12 ел. Әмма бу – бары тик сан гына. «Кияүгә чыкканда да, тормыш көткәндә дә яшь аермасы сизелми», – ди ул.

Мөхәммәтҗановлар Энҗе, Булат, Лилия, Нәфисә һәм Мәдинә исемле балаларга гомер биргән. Нәфисә – 1 сыйныф укучысы, Мәдинә балалар бакчасына йөри. Олы кызлары Энҗе үзе дә әни инде. Фельдшер һөнәрен үзләштергән. Булатка 23 яшь, ул – инженер-механик. Лилияләре РКБда эшли.

– Мин үземне ике буын баласын тәрбиялим дип уйлыйм. Оныгым белән кечкенә кызымның яшь аермасы – 2 яшьтә 2 ай, – ди бәхетле ханым. – Олыларын үстергәндә бөтен эшне эшләргә кирәк иде: мичкә утын ягасы, мунчага, өйгә су ташыйсы, кер юасы, көтүгә чиратлашып чыгасы. Мин социаль хезмәткәр булып эшлим. Әби-бабайларга бәрәңге утыртырга, өй юарга, вак-төяк эшләре булса, гел өч балам белән бергә йөри идем. Алар беркайчан да «юк» дип әйтә белмәде. Гел хезмәттә булдылар. Дини тәрбия дә бирдек. Хәзер тормыш Аллаһка шөкер генә бит! Су ташымыйбыз, мунча якмыйбыз, кер юмыйбыз, идәнне дә робот юа...

Күпбалалы әнидән хәтерендә уелып калган 8 Март бәйрәме турында да сорадык.

– Өченче кызым туып, роддомда идем. 28 февраль бу. Ул вакытта унар көн ята идек бит. Тормыш иптәшем 8 Март бәйрәме белән котлап, бүләкләр күтәреп килгән иде. Әнә шул истә калган, – дип сөйләде Алсу апа. – Миңа балаларым гел сюрприз ясап кына тора. Ел да зур бүләкләр ясыйлар. Быел туган көнемә өчесе бергә җыелышып гомрә хаҗына юллама бүләк иттеләр. Гомерем буена истә калырлык иң олы бүләк бу минем өчен!

Тормышыннан бик канәгать Алсу апа.

– Мин үземне иң бәхетле әни, бик бәхетле хатын дип саныйм. Аллаһы Тәгалә яман күздән сакласын. Нәрсә әйтсәм дә, тыңлаучан балаларым, сүземә колак салучы, хөрмәт итүче ирем бар! Киявем дә бик әйбәт, кода-кодагыйларым да бер дигән. Балаларым дус-тату, аралашып, бер-берләренә кунакка йөрешеп яши, – ди ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Әни, кайгырма!

Балтач районының Бөрбаш авылында гомер итүче Мәгъфирә апа Әсхәдуллина ике улын махсус хәрби операциягә озатa. Алар ире белән бер кыз, өч малайга гомер бирәләр. Малайларның да ниндиләре бит: өчесе дә игезәкләр! Заманына күрә авыр чаклар бит әле. Киендерәм дисәң, кием юк, ашау-эчү дә бүгенге кебек иркен түгел. Әмма ул бер дә зарланмый, дүрт баласын да берүзе аякка бастыра.

– Кыз баланың язмышы шул инде аның. Монда килеп эләгүемне сизми дә калдым. Әмма бик рәхәт яшәдем һәм яшим. Авылдашларым да, райондашларым да – терәк. Үземнекеләр дә ташламый. Сыйныфташлары да Арчадан кадәр килеп хәлемне белешеп тора, – ди 66 яшьлек Мәгъфирә апа.

Өч улының икесе махсус хәрби операциягә чакырылган.

– Өч улым да бергә армиядә хезмәт иттеләр. Өлешчә мобилизация башлангач, Балтачта яшәүче ике улыма шундук повестка килде. Илнар белән Ленар беренче көннән үк шунда. Динар да китәргә җыенган иде. Әмма аны чакырмадылар, – ди Мәгъфирә апа. – Ул чаклардагы хәлләремне белсәгез! Сыгылдым да төштем. Бик борчылдым. Күз алдымнан уларымның кечкенә чагы узды. Шунда җибәрер өчен үстердемме сезне, дип, еламаган көнем булмады. Уларымның нык булуы мине көчле итте.

Ана өчен иң авыры – уларының алгы сызыкта булган көннәре. 20шәр көн берниндн хәбәр булмый бәгырь җимешләреннән. Ананың укымаган догасы калмый. «Балаларымны югалттым», – дип елаган чаклары күп була...

– Илнарым бик каты яраланды. Анда да үлеп терелдем инде. Исән калуына сөендем. Әмма күпме сәламәтлеген югалтты. Уларымның гаиләләре бар. Илнарымның – ике баласы, Ленарымның сабыена 2 генә яшь әле, – ди Мәгъфирә апа. – Алар үзләре гел: «Әни, кайгырма!» – дип кенә тордылар. Ничек инде борчылмыйсың! Ана бит мин! Сабыйларымны ялгызым аякка бастырган кеше бит мин. Алар дүртесе дә миңа бик газиз.

Мәгъфирә апа баласын көткән һәр анигә сабырлык тели. Гомерләре бетмәсен, дип кабатлый.

– Бәйрәмнәрдә чәчәкләр дә, бүләкләр дә көтмибез. Газиз балаларыбыз исән булса, шул җитә безгә. Кайчакта өч-дүрт көнгә бер тапкыр улым: «Әни, бар да яхшы», – дигән хәбәр сала. Шул сүзләр канатлар куя инде! Көннәрем яктырып китә, ризыклар тәмләнә, яшисе килә башлый, – ди ул. – Күпме әниләрнең балалары бүген ил сагында. Мондагылар тыныч тормышта яшәсен, сабыйлар бәхетле булсын, ди алар. Ничек инде горурланмыйм ди?! Ана өчен баласының илне саклавы – зур горурлык! Инде алдагы көннәремдә дә балаларымның игелеген күреп, аларның бәхетенә сөенеп яшәсәм иде, дим.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЧӘЧӘГЕМ СИН, ГӨЛЕМ СИН

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сигезенче мартны чәчәкләрсез күз алдына да китереп булмый. Якыннарын сөендерү өчен, ир-атлар иң матур гөлләмәләр сайларга тырыша. Ә тәкъдим, кем әйтмешли, баштан ашкан. Ипи кибетендә дә, базарда да, юл чатында да чәчәк саталар бу көннәрдә. Бәяләре дә нык аерыла. Аллы-гөлле чәчкәле Казан урамнарыннан «ВТ» хәбәрчесе дә әйләнеп кайтты.

Бәясе көн саен арта

Башкаланың Җиңү проспекты базарына җиткәнче үк, ерактан матур көй яңгырап тора. Әнә бәйрәм рухын ничек күтәрәләр. Базар эче исә тулы бер чәчәк ярминкәсен хәтерләтә. Ел әйләнәсе җиләк-җимеш сатучы агайлар да, гадәти товарларын эчкәрәк этеп, беренче рәткә лалә чәчәкләре тезгән.

– Лалә чәчәге – бәйрәм төсе. Ал, кызым, – ди сатучы. – Өч чәчәкле бәйләм 500 сум тора. Бүген иртән генә Казан янәшәсендәге теплицадан китерделәр. Өйдә әле озак сакланачак.

«ГАЗель»дән сату итүчеләрдә лалә арзанрак тора. Чәчкәләрнең зурлыгына, төсенә һәм төренә карап, бәясе 110 сумнан башлана.

– Бүген иртән күмәртәләп сату базасыннан бер машина чәчәк алып килгән идек, сатып бетердек. Монысы да кичкә кадәр калмаячак. Кочак-кочак чәчәк сатып алалар, – ди сатучы. – Бәясенә дә карап тормыйлар. Былтыр бер лаләне уртача 80–90 сумнан саткан идек. Быел чәчәк кыйммәт. Моны санкцияләргә бәйләп аңлаталар. 8 Мартка чәчәкнең күбесен Казахстан аша алып кайтканнар.

Быел мимоза сатучылар лалә сатучылардан да күбрәк. Сары төстәге әлеге чәчәкне базарга тартмалар белән ташып кына торалар.

– Мимоза ул – яз килү билгесе. Төсе дә кәефне күтәрә, – дип, товарын мактарга керешә Наҗия апа. – Мин хатын-кызларга баш киемнәре сатам. Иш өстенә куш дигәндәй, чәчәк бизнесына да кереп киттем әле. Бик яхшы алалар. Шулай булмый ни, быел чәчәк кыйммәт. Ә мимозаның бер ботагы – 150 сум.

– Әле иртән генә 100 сум иде бит, – дип, сөйләшүгә кушылды янәшәдә генә яулык сайлап басып торган апа.

– 8 Март көнне 300 сум булачак, – дип пышылдады Наҗия апа.

Өстәлдә ятучы мимоза бәйләмнәрен рәтләп: «Әле калса», – дип тә өстәде.

Бер читтәрәк чәчәкләрне бизәкле тартмаларга да тутырып саталар иде. Баксаң, бу – сабыннан ясалган гөлчәчәкләр икән. Чын чәчәктән аерып та булмый.

– Чәчәк шиңә, ә безнең бүләк һәрвакыт күңелне иркәләп торачак, – ди сатучы.

Хуш исле тартмаларның бәясе 600 сумнан башлана. «ВТ» хәбәрчесе басып торган арада гына да, өч кеше: «Хезмәттәшләргә шәп бүләк», – дип, икешәр тартма сабын чәчәк сатып алды.

Пычкы-чүкеч алыр чак түгел

Чәчәк бәяләрен белешергә теләп, кибетләргә дә кердек. Азык-төлек кибетләрендә касса янында торучы лалә бәйләмнәре белән әллә ни кызыксынучы күренми. Ә менә зур гипермаркетларда чәчәк бәйләмнәре янына якын да килә торган түгел. Төзелеш материаллары сатучы кибетләрнең берсендә, мәсәлән, биш данәле лалә бәйләме 238 сум тора. Дөрес, чәчәкләре ачылып кына килә әле. Тик товарны киштәгә чыгарырга да өлгермиләр, шундук әрҗәсе белән зур кәрзингә салып куялар.

– Яңа өзелгән чәчкәләр Мәскәүдән кайта. Кичтән җыелы суга утыртыгыз, иртә белән үк ачылып китәчәкләр, – дип киңәш итә сатучылар. – Озаграк сакларга теләсәгез, төнгә суыткычка куярга мөмкин. Тик тигез өслеккә яткырырга кирәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Мартта – «урак өсте»

Илнур ЛАТЫЙПОВ, Балтач районының Смәел авылында чәчәк үстерүче:

– Чәчәкне теплицада ел әйләнәсе үстерәбез. Төгәл саны юк, ел фасылына карап, бездә төрле гөлләр үсә. Смәелдә җылытылган, ел әйләнәсе эшли торган ике теплицабыз бар. Чәчәкләрнең төренә килгәндә, аларга сорау ел фасылына бәйле. Мәсәлән, көз көне хризантемалар күпләп сатабыз. Яз көне – лалә, әлбәттә. 8 Март бәйрәменә чүлмәкле гөлләр сораучылар да күп. Аларны да үстерәбез. Дөньякүләм хәлләргә бәйле рәвештә, хәзер орлык алып кайту бик катлауланды. Бу исә ахыр чиктә чәчәкнең бәясендә чагыла. Үзегез күреп торасыз: гөлләмә бәяләре елдан-ел кыйммәтләнә. Лалә чәчәге суганчасы, мәсәлән, урау юлар белән чит илләрдән кайта. Аның сыйфаты да начарланды. Без генә хәл итә алырлык мәсьәлә түгел шул бу. Илдә орлыклар селекциясе белән шөгыльләнүче оешмаларны санарга кул бармаклары да җитә. Көньяк төбәкләрдә моның өчен шартлар бик яхшы, әлбәттә. Әмма вакыт кирәк. Голландиядә, мәсәлән, лалә суганчасын 300 елдан артык үстерәләр. Димәк, аларның 300 еллык тәҗрибәсе бар. Чәчәк үстерү бер дә җиңел түгел. Карамасаң, берсе дә үсми. Аларны вакытында урнаштырып бетерергә дә кирәк. Ярар, киләсе елга сатарбыз дип, складка тутырып куеп булмый бит. Чәчәкләр үстерү минем өчен бизнестан бигрәк, яраткан шөгыль кебек ул. Матурлык тудыргач, күңелгә рәхәт.

Рания ШӘРӘФИЕВА, Казанда чәчәк кибете хуҗасы:

– Чәчәкләргә бернинди кытлык юк. Дөрес, чит илләр ябылгач, бәясе бик нык кыйммәтләнде. Чөнки хәзер сатудагы чәчәкләрнең 70–80 проценты диярлек урау юллар белән кайта. Иң сыйфатлы гөлчәчәкләрне, мәсәлән, Кения һәм Эквадорда үстерәләр. Аларның чәчәк бөреләре зур, озак саклана. Лалә, лилия, гладиолус кебек чәчәкләр Белоруссия аша кайта. Хәер, лаләне Мәскәүдә дә бик күпләп үстерәләр хәзер. Илнең көньягындагы чәчәк патшалыкларын әйткән дә юк. Бер данә лаләнең үзкыйммәте 40–45 сумнан башлана. Чәчәк сатучыларның «урак өсте» елга өч кенә инде ул: Белем көне, Әниләр бәйрәме һәм 8 Март. Былтыр март аенда гадәттәгедән өчләтә күбрәк чәчәк саттык. Бу көннәрдә дә тәүлек әйләнәсе эшлибез. Ярдәмгә тагын бер сатучы ялладык. Ишеткәнсездер, социаль челтәрләрдә: «Быел чәчәк сатып алырга ярамый, гөлләмә аша агуларга мөмкиннәр», – дигән имеш-мимешләр дә таралды. Тик гүзәл затларны сөендерергә теләүчеләр моның ише хәбәрләрдән курыкмый. Шикләнәсе дә юк. Бу – сафсата. Чәчәк ул – шундый ук товар, аның бөтен документлары бар. Ә менә исенә килгәндә, әйе, хәзер чәчәкләр элеккеге кебек хуш исле түгел. Соңгысы җитештерү технологияләре үзгәрүгә бәйле.

Энә дә – бүләк, ир-ат та...

Ир-атларның хатын-кызлар өчен күп нәрсәгә әзер булуын чамалыйсыздыр инде, тик интернеттагы тәкъдимнәр шаккатыра. Мондый игъланнарга без дә күз салдык.

Игъланнар сайтында «8 Мартка нәкъ шул татар»ның иң арзанлы хезмәте 5260 сум тора. Казанда яшәүче урта яшьтәге түбәтәйле ир-ат, фотосурәте үзенеке булса, әлбәттә, мондый хезмәтне ни өчен тәкъдим итүен дә аңлаткан. Бәйрәм көнне 101 гөлчәчәк тоткан бәхетле хатын-кызларның сторисларын карап утырырга теләмәүчеләргә бу! Озын сүзнең кыскасы, «нәкъ шул татар» белән социаль челтәрләр өчен фотога төшү – 5260 сум, башкаладагы рестораннарның берсенә барып чәй эчеп кайту – 21600 сум (ашау-эчү сезнең хисапка), кайчан кияүгә чыгасың инде дип аптыратмасыннар өчен, әби белән танышу – 15000 сум, көнне бергә үткәрү 48100 сум тора. Үзең сатып алган чәчәкне 14400 сумга бүләк итә дә ала әле ул. Бер тәүлек эчендә әлеге игъланны 1 меңгә якын тапкыр караганнар.

Бәйрәм көнне «шәхси машина йөртүче»гә дә заказ бирергә мөмкин. Артур исемле егет, мәсәлән, 4600 сумга Казан буйлап 2 сәгать йөртеп кайтырга риза. «Шәп әңгәмәдәш һәм яхшы музыка» да вәгъдә итә ул.

Фотосурәттә мускулларын күрсәтеп төшкән Николай исә бергә селфи төшкән өчен 500–2000 сум акча сорый.

Сораштыру

8 МАРТКА НӘРСӘ КӨТӘСЕЗ?

Чәчәк	34%
Акча	28%
Акчалы сертификат	25%
Косметика яки парфюмерия	13%
Кием-салым	8%
Берни дә кирәкми	5%

(Февраль азагы – март башында Идел буе федераль округында яшәүче хатын-кызлар арасында үткәрелгән сораштырудан)

11 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Халкым минем…» 12+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Трибуна «Нового века» 16+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00, 01.40 «Таяну ноктасы»
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «КАПКАН ДЛЯ ЗВЕЗДЫ» 12+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Җырлыйк әле!» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ПЕРЕВЕДИ ЕЁ ЧЕРЕЗ МАЙДАН» 16+
22.55 «Большая игра» 16+
00.00 «Александр Проханов. Исповедь» 18+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.55 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 16.50 Новости
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска». Новый сезон 12+
00.00 «Звезды сошлись» 16+
01.40 «Основано на реальных событиях» 16+
03.20 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.50 «Пять ужинов» 16+
10.05 «ПОВОРОТ СУДЬБЫ» 16+
14.35 «ОДНО ЦЕЛОЕ» 16+
19.00 «ДОБРОТА 16+
22.45 «КОШКИН ДОМ» 16+
02.30 «НАПАРНИЦЫ» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «СЛУШАТЬ В ОТСЕКАХ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Моторы и колеса» 12+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 12+
14.00 «Улика из прошлого» 16+
14.50 «Скрытые угрозы» 16+
15.40 «Секретные материалы» 16+
16.30 «Загадки века» 12+
17.20 «Специальный репортаж» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.55 «ЗЕЛЕНЫЙ ФУРГОН» 12+
02.25 «Часовые памяти» 16+
03.20 «Москва фронту» 16+
03.40 «ВИКИНГ» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары **Гыймаев** Илшат Сәхәп улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен Казан шәһәре Идел буе районының «19 нчы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе укытучысы **Нуретдинова** Галия Юнис кызына; «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең «Н.И. Лобачевский исемендәге лицей» гомуми белем бирү интернат-мәктәбе укытучысы **Романова** Ольга Николаевнага; Казан шәһәре Мәскәү районының «Гармония» 20 нче гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укытучысы **Сәлимова** Зәйтүнә Мөфарәк кызына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Метеорология өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары **Немцева** Татьяна Геннадьевнага Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган метеорологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Баулынефть» нефть-газ чыгару идарәсенең нефть һәм газ чыгару буенча операторы **Галәүтдинов** Илшат Рәшит улына; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Скважиналарның җир астындагы өлешен ремонтлау идарәсе Лениногорск скважиналарның җир астындагы өлешен ремонтлау цехының скважиналарның җир асты өлешен ремонтлау буенча операторы **Гущин** Константин Евгеньевичка; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Скважиналарның җир астындагы өлешен ремонтлау идарәсе Азнакай скважиналарның җир астындагы өлешен ремонтлау цехының скважиналарны ремонтлау (капиталь, җир астындагы өлешен) буенча мастеры **Халиков** Илдар Муллашәех улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Физик культура һәм спорт өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт районының йөзү федерациясе» җирле иҗтимагый оешмасы башкаручы директоры **Шәйхаттаров** Ринат Аделҗан улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Төзелеш өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Транспорт корылмаларын проектлау институты» акционер җәмгыятенең баш геодезисты **Хәмитов** Таһир Ильяс улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Энергетика өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе нефть чыгару объектларының җылылык-энергетика җиһазларыннан файдалану һәм аларны ремонтлау буенча төркемнең әйдәп баручы инженеры **Чернявская** Ирина Анатольевнага Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ХӘЙРИЯЧЕ РАФАЭЛЬ ЯРУЛЛИН:

«БУ ЭШКӘ ТОТЫНГАЧ, ХАТЫНЫМ БАЛАГА УЗДЫ»



«Көнгә 100 кеше ашатабыз», – ди Рафаэль.

Монда кемнәр генә юк! Баласы өеннән куып чыгарган аналар да, гаиләсенә керәге калмаган ирләр дә, пенсиясен җиткерә алмаган өлкәннәр дә... Арада торыр җире булмаган яшьләр дә күренә. Барысын да бер уй – тамак туйдыру берләштерә.

Якшәмбе җиткәнне көтеп тора алар. Бөгелмәдә яшәүче 42 яшьлек эшмәкәр Рафаэль Яруллин аларны атна саен ризык белән сыйлый.

– Арабызда нинди генә язмышлы кешеләр юк икән. Кайчагында аларны тыңлап, хәйран каласың. Бу эшемне башлаганчы, шәһәрдә хәер сорап торучыларны еш очрата идем. Авыр хәлдә калган кешеләрне җылы ризык белән сөендерергә теләдем. 2020 елда, ниһаять, теләгемне тормышка ашыра башладым, – ди Рафаэль.

Рафаэль төзелеш өлкәсендә эшли, буш вакытларында агачтан әйберләр ясый. Кайчагында заказ буенча ит ризыклары да пешереп сата икән.

– Әнә шул акчага якшәмбе көнне ишегалдымда зур казанда ризык пешерергә булдым. Әкренләп ишетеп килә башладылар. Башта 10 кеше килсә, аннан 25кә, соңрак 50гә дә җиттеләр. Җәй көннәрендә 100дән артып китәләр. Бу эшемне күреп, башкалар да кушылды. Беркемнән дә акча сораганым булмады. Үзләре теләк белдереп, кемдер ит, кемдер яшелчә алып килә. Соңгы арада чәй ризыклары да китерүчеләр күп. Сәдака итеп камыр ризыклары да бирәләр, – ди ул. – Әле менә шушы көннәрдә бер ир-ат баласы туган хөрмәткә сарык ите бирде. Шул иттән пылау пешердек. Ашатып кына калмыйбыз, кирәк кешегә кучтәнәч итеп тә җибәрәбез. Мохтаҗларга өләшү өчен бүләк алып килүчеләр дә бар. Әле менә бу арада балык тараттык.

Бирердә бар кешегә дә ишекләр ачык. Әле менә салмышларга айныгач килергә киңәш итәләр. Ризык эзләп килүчеләр арасында яшьләр дә җитәрлек. Рафаэль андыйларга ипине үзләренә эшләп ашарга ярдәм итә. Эшмәкәрләр, колхоз җитәкчеләре, фермерлар белән сөйләшеп, эшкә урнаштыралар икән.

– Җылы ризык эзләп килүчеләр арасында 12 мең сум пенсия алучылар бар. Төрле авырудан интеккәннәре дә аз түгел. Менә уйлап карагыз: 6 мең сум акчасын коммуналь хезмәтләр өчен түли, калганына ай буе җан асрарга кирәк. Әле дарулар да аласы бар. Иң борчыганы шул: бу кешеләрнең балалары ни карый? Әти-әниләрен шундый көнгә калдыру өчен нинди кеше булырга кирәк? Менә нинди көнгә килеп җиттек! Кайчак өлкәннәрне гаиләгә дә урнаштырмакчы булып карыйм. «Алам» дип шалтыратучыларның күбесе авыру әниләрен карар өчен кеше эзли булып чыга. Шаккатам мин андыйларга. Үз әниеңне карарга вакыт таба алма инде! Сизәсезме, бик усалландык без... Урамдагы чит кешене әйтмим инде, якыннарга да җылы сүз таба алмыйбыз бит, – ди Рафаэль. – Әлеге эшне башлаганда мин бернигә өметләнмәгән идем. Йөрәгем кушканга алындым. Ә бер айдан хатыным балага узды. Мин моны эшемнең кабул булуы, кешеләрнең рәхмәте дип кабул иттем. Киләчәктә мохтаҗлар өчен ашханә ачасым килә. Атнага бер түгел, 2–3 тапкыр ашатасы иде үзләрен. Ярдәм кулы сузучыларга рәхмәт. Башкаларның да яхшылыкка кушылуына сөенәм.

ЙӨРИ АЛМАСА ДА, ЙӨГЕРӘ

Казанда яшәүче 19 яшьлек Элина Әхмәтованы күпләргә үрнәк итеп куярга була. Тормыш авырлыкларына бирешмичә, үз юлын ерып баручы кыз ул. Ә бит берәү булса, елап, урыннан да тормас иде. Ә ул исә ничек тә тормышның якасына ябышып яшәргә тырыша.

Туганда ук имгәнә ул. Табиблар да артык өметләндерми, кызның үз аягында йөри алмаячагын әйтәләр.

– Мин аны олыгаеп кына таптым, көтеп алган бердәнбер балам. Табибларның, балагыз авыру, дигән сүзе бар хыялларны җимергәндәй булды. Әмма иремнең һәрвакыт янәшә булуы, туганнарымның ярдәм итүе миңа яшәр көч бирде. Бар көчемне кызымны дәвалауга бирдем. Кая гына йөртмәдек. Без бармаган тернәкләндерү үзәкләре калмады. Аның ярдәмгә мохтаҗ булып утыруын теләмәдем. Кызымны ничек тә аякка бастырасы килде, – дип сөйли әнисе Светлана.

Шөкер, тырышлык бушка китми. Элина дөрес итеп сөйләшә, акылына зыян килмәгән, башы бик әйбәт эшли. Тик менә аяклары гына тыңламый. Кызның исә барыбер бирешәсе килми. Ул хәтта арбага утырудан да баш тарта, ходунки белән йөри башлый.

– Иң зур бәхетем – янәшәмдә сау-сәламәт дусларым булу. Яшермим, кайчак мин алар кебек булмавымнан читенсенеп тә куям. Башны аска игән чаклар да була. Әмма дусларым күңелсезләнергә ирек бирми. Әле бер җиргә чакырып алалар, әле икенчесен ияртеп баралар. Беләсезме, аяклар авыртса да, тик утыра белмим мин, – ди Элина.

Кыз 9 сыйныфны тәмамлагач, Казан сәүдә техникумына укырга керә. Быел диплом алырга җыена. Кечкенәдән йөзүгә йөргән. 6 ел буе ныклап шөгыльләнү аның холкын да үзгәрткән, сәламәтлеген дә ныгыткан, көчле дә иткән.

– Хәзер инде йөзүгә йөрмим. Вакытым җитми. Үземне төрлечә сынап карыйм. Үзлегемнән төрек телен өйрәндем. Хәзер инде башкаларга дәрес бирәм. Шуннан җаныма рәхәтлек табам. «Абилимпикс» бәйгесендә катнашып, туризм юнәлеше буенча җиңү дә яулаган идем, – ди ул.

Кызганыч, әтисе кызының уңышларын күреп өлгермәгән. Моннан ике ел элек вафат булган.

– Ирем башта ковид белән авырды. Инде узды бугай дигәндә генә табиблар бавырында үзгәрешләр күреп алды. Анализлар яман чир икәнен күрсәтте. Зарланганы юк иде. Тик чир үзенекен итте. Ирем тиз арада сулды. Аны югалту бик авыр булды. Минем кебек үк бар гомерен балабызга багышлады ул. Башкаларның ирләре ташлап та китә бит әле. Тик минеке алай эшләмәде. Бердәнбер кызыбызны икәү бергә тәрбияләдек. Икебез дә яраттык. Исән булса, Элинага карап горурланыр иде, – ди Светлана.

> Мин – хыялый кеше. Минем өчен булдыра алмаган әйбер юк. Тормыш девизым да шулай. Куркып тормыйм. Булдыра алмасам, кабат тотынам. Әмма барыбер җиренә җиткерәм. Мөмкинлекләрең чикле булса да, булдыра алмыйсың дигән сүз түгел. Тырышырга кирәк.

– Башкалар кебек мин дә үз ярымны көтәм. Аның белән балалар үстерәсем килә. Язмыш ниләр әзерләгәндер, белмим. Әмма минем планнарым шундый. Аларны тормышка ашырып булыр дип уйлыйм. Башкаларга шуны киңәш итәм: бирешмәгез! – ди кыз. – Гомер бер генә бирелә. Мин башкаларга охшамаган икән, димәк, сәбәбе бар. Юкка түгел бу! Булган кимчелекне дә яратып кабул итәргә кирәк. Аның турында уйлап та утырмагыз. Элек әнием минем өчен барысын эшләсә, хәзер һәр уңышыма сөенеп кенә тора. Минем әле аны картайган көнендә бәхетле итәсем, рәхәттә яшәтәсем бар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ТАТАРЧА «ПӘРӘВЕЗ»

ӨЧПОЧМАК ҺӘМ УЕН-КӨЛКЕ БЕЛӘН ТУЛГАН ИНТЕРНЕТКА НИЧЕК АКЫЛ КЕРТЕРГӘ?

«Ватаным Татарстан» редакциясе каршында оешкан «Туган тел» клубының чираттагы утырышы интернетта татарча мохит темасына багышланды.

«Түгәрәк өстәл»дә КФУның гомуми тел белеме һәм төркология кафедрасы доценты **Кадрия ФӘТХУЛЛОВА**, Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты лексикография бүлеге мөдире **Ринат СӘФӘРОВ**, Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе **Райнур ХӘСӘНОВ**, Рус телендәге «Идел» журналының шеф-мөхәррире, интернетта популяр булган «Че гуглит татар кызы» проекты авторы **Динара ЗИННӘТОВА**, Яндекста аналитика бүлеге җитәкчесе, ясалма интеллект белгече **Сәйдәш МИФТАХОВ** катнашты. Утырышны «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире **Гөлнара САБИРОВА** алып барды. Сезнең игътибарга анда яңгыраган фикерләрне тәкъдим итәбез.

:: Фикер алышуны татарча интернетның бүгенге торышына бәя бирүдән башлыйсы килә.

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Әлегә ул заман таләпләреннән бик ерак. Татар интернеты татар халкының бөтен мәнфәгатьләрен дә кайгыртa дип уйлыйбыз икән, нинди генә мәсьәлә чишмик, без интернетта татар телендә мәгълүмат табарга һәм аны эшкәртә алырга тиеш. Кызганыч, бүген, әйтик, креатив индустрия һәм фән өлкәсенә кагылышлы татарча мәгълүмат табып булмый. Әмма күпмедер активлык бар. Блогерларыбыз, татарча массакүләм мәгълүмат чараларыбыз бар, иң көчле ясалма интеллектларның берсенә татарча сорау бирсәк, ул безгә татар телендә җавап бирә. Ул бик күп нәрсәне белеп бетерми. Димәк, без интернетта бар.

Ринат СӘФӘРОВ:
– Әлбәттә, без татар телен дөньяда киң таралган телләр белән берничек тә чагыштыра алмыйбыз. Россиядә яшәүче, республикалары булган башка халыклар яссылыгында карасак, әйе, бездә хәлләр күпкә яхшырак булып тоела. Әмма татар интернетының хәлен уртачадан түбән дип бәяләр идем. Интернеттагы татар телле мәгълүмат, нигездә, татар теле,

мәдәнияте белән чикләнә. Дөнья хәбәрләре, фән һәм башка тармакларны карасак, татар телендә баштан ук язылган яки тәрҗемә ителгән мәгълүмат юк. Бу – безне изоляциягә китерә торган вазгыять дип саныйм.

Райнур ХӘСӘНОВ:
– Интернетка, аерым алганда, социаль челтәрләргә кереп карасак, татар телле контент бар, ләкин аның күбесе яшьләргә кызыклы түгел. Күпчелек контент татарлар турындагы стереотипларга кайтып кала. Әйтик, интернетта өчпочмак, чәкчәк темасы бик популяр. Булсын ул, ләкин без моның белән генә чикләнергә тиеш түгел. Күңел ачтыра торган контент белән беррәттән файдалысы да булырга тиеш. Башка телләр белән чагыштырсак, бу өлкәдә бездә бушлык бар. Без бу бушлыкны ясалма интеллект мөмкинлекләрен файдаланып тутыра алабыз. Әйтик, күптән түгел әзер сценарий нигезендә фильм төшереп бирә торган ясалма интеллект эшли башлады. Һәм ул бер төркем кешеләр төшергән фильмнардан бер дә калышмый. Нигә әле бу мөмкинлекне татарча фильмнар төшергәндә файдаланмаска?

:: Интернетта татар телен онлайн өйрәнүгә ихтыяҗ зурмы? Һәм моның өчен нинди мөмкинлекләр бар?

Кадрия ФӘТХУЛЛОВА:
– 10 ел дәвамында «Ана теле» онлайн мәктәбе эшләп килде. Әлеге проект урнашкан платформа Россиядән китү сәбәпле, узган ел ул эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр булды. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгында әйтүләренчә, әлеге проект кысасында җитештерелгән контентны Россия платформасына күчерү, мобиль кушымтасын булдыру буенча сөйләшүләр алып барыла. Без әлегә өметне өзмибез.

Моннан тыш, бүген тагын берничә онлайн мәктәп, аерым укытучыларыбыз бар. Без алар белән аралашып торабыз. Әйтүләренчә, эшләре тукталып тормый, Россиядә дә, чит илләрдә дә татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ бар.

Динара ЗИННӘТОВА:
– Татар телен өйрәнергә теләүчеләр, татарча контент белән кызыксынучылар, чыннан да, күп. Бу җәһәттән татарчалы-русчалы контент файдалы булыр иде. Ул рус телендә сөйләшүче кешеләрне җәлеп итәргә, аларны телебез белән кызыксындырырга ярдәм итә. Татар телен камил белмәгән кешеләр дә, ул контентны аңлап, аңларга тырышып, тел белән күбрәк кызыксына. Һәм мин андый контентка карата тәнкыйтьне аңлап бетермим. Аннан соң, татарчасы артык яхшы булмаган кешеләрнең татар телендә сөйләшүенә бәйләнеп, аларны тәнкыйтьләүчеләр дә азрак булсын иде. Ул тәнкыйтьчеләргә я бик яхшы булсын, я бөтенләй булмасын. Алай мөмкин түгел. Мондый тәнкыйть тел белән кызыксынучыларның бөтен теләген бетерә, миңа калса.

:: Бүген интернетта халыкның куллану даирәсе күбрәк язмыш, шоу-шу, эстрада кебек популяр темалар белән чикләнә. Интернетта җитди контент булырга тиеш, дисез, ә менә шушы каршылыкны ничек җиңәргә? Гомумән, кулланучылар арасында мондый контентка ихтыяҗ бармы?

Динара ЗИННӘТОВА:
– Без халыкны тәрбияли, моңа ияләндерә алабыз. Ягъни аңа таныш булган, ул интернетта күрергә күнеккән контент, образлар аша кызыксындырырга мөмкин. Шул ук җитди темаларны җиңелрәк контент, юмор аша тәкъдим итәргә була.

Ринат СӘФӘРОВ:
– Кайсы гына милләтне алсаң да, без сөйләшкән фән, милләтне саклау, телне үстерү кебек темалар нинди дер массалы күренеш була алмый дип уйлыйм мин. Ул – халыкның ничәдер процентын гына борчый торган мәсьәләләр. Бәлки, андый кешеләр өчен аерым контент булырга тиештер? Ә калганнарга җиңелрәк форматта җиткерү юлыннан барырга мөмкин. Ләкин бу шулай ук җитди, эзлекле рәвештә эшләнергә тиеш. Бездә шул ук күңел ачу форматы, юмор да профессионаллар тарафыннан эшләнми бит.

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Маркетингта «бүрәнкә» («воронка») дигән төшенчә, система бар. Бу мәсьәләдә безгә нәкъ менә «бүрәнкә» булдырырга кирәк. Ягъни безгә башта чагыштырмача җиңел, массалы, татарчалы-русчалы контент аша аудитория тупларга кирәк. Ул бик күп булырга тиеш. Аннары шул аудиториягә бары тик татар телендә булган, милли контент тәкъдим итәргә, бераздан аны тагын да катлауландырырга, интеллектуаль контентка якынайтырга, ә соңыннан җитди, интеллектуаль контентка күчәргә. Әмма башта ук аудитория туплый алмасак, катлаулы, җитди татарча контент белән кызыксынучы булмаячак. Безгә бу эшне тулысынча, системалы рәвештә эшләргә кирәк.

:: Бу эштә дәүләтнең роле нинди булырга тиеш? Татар интернетына дәүләт тарафыннан игътибар җитәме?

Динара ЗИННӘТОВА:
– Безгә тел амбассадорлары җитми. Аларны үстерү һәм тәрбияләү эшендә дәүләт ярдәм итә алыр иде дип уйлыйм. Амбассадор, дигәндә, мин интернетта татар телен белүнең уңай яклары турында сөйләүче, үз мисалында күрсәтүчене күз уңында тотам. Ул нинди дер тулы бер образ булырга, ә кешеләр шул образга омтылырга тиеш.

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Бу фикер белән килешәм. Дәүләт роленә килгәндә, миңа калса, без амбассадор дип атаган кешеләрне берничи акча да алыштыра алмый. Әгәр күпмедер акчага нинди дер проект гамәлгә куела икән, акча бетүгә, ул проект бетәчәк. Бу очракта шул ук ярдәм чараларын амбассадорларга юнәлтергә, шул рәвешле шәхесләр үстерергә кирәк дип саныйм. Нинди дер төгәл рецептым юк. Ләкин шәхесләр, гадәттә, нинди дер җәмгыятьләр, бергәлекләрдә табыла. Миңа калса, безгә төрле өлкәләргә караучы җәмгыятьләр булдырырга кирәк.

Ринат СӘФӘРОВ:
– Дәүләт тә нәкъ шуны эзлидер сыман. Җитәкчеләр тарафыннан кызыксыну юк дип әйтә алмыйм. Алар һәрвакыт нинди дер инициатива көтә, аларга да шундый шәхесләр кирәк. Әмма алар да, без дә ул шәхесләрне ничек үстерәсен белмибез. Татар телен үстерергә теләүчеләр юк түгел бит.

Райнур ХӘСӘНОВ:
– Алар күп, дөресен әйткәндә. Алар әлләнинди проектлар эшли, ләкин игътибар үзәгеннән читтә кала.

Кадрия ФӘТХУЛЛОВА:
– Миңа калса, бу процессны ничектер тизләтергә кирәк. Безнең халык пассив. Менә шушы дөньяга кереп китәргә әзер түгел, бик консерватив ул. Бу пассивлык безгә киң җәелеп китәргә ирек бирми. Дәүләтне гаепли алмыйм, безгә бик күп мөмкинлекләр бирелгән, ә менә инициатива җитеп бетми.

:: Амбассадорлар темасын дәвам иттерсәк, бүген татар блогерлары бу миссияне үти аламы? Аларны моңа җәлеп итәр өчен нишләргә?

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Алар беренче чиратта үтәргә тиеш. Кызганыч, бүгенге татар блогерларының контенты гадәти тормыш, авыл хәлләре, өчпочмак, чәкчәк, Сабан туена гына кайтып кала. Менә бу даирәләрнең амбассадорлары күп, шуңа алар турында яхшы беләләр. Мондый контент та булсын, әмма безгә, һичшиксез, яңа юнәлеш блогерлары тәрбияләргә кирәк. Бәлки, моның өчен ниндидер махсус курслар уйлап табаргадыр? Һәм алар күп булсын иде.

Гөлнара САБИРОВА:
– Безгә, чыннан да, бу юнәлешкә караган белгечләрне чакырып, курслар уздырырга кирәк. Татарлардан гына түгел, башка милләтләрдән дә өйрәнә алабыз. Бәлки, ул дәүләт югарылыгындагы җитди проект булырга тиештер.

Динара ЗИННӘТОВА:
– Аннан соң бездә пиар, маркетинг ягы да аксый. Җитди контент булдырсак та, аны таратырга кирәк бит әле. Әйтик, пиар белән шөгыльләнүче зур агентлыкларга дәүләт ярдәмендә татар телле контентны тарату бурычы куярга була.

:: Татарстан – IT тармак буенча иң алдынгы төбәкләрнең берсе. Бу көннәрдә «Киләчәк уеннары» узды. Менә шундый республикада татар телле интернетны үстерү турында сөйләшү хәттә берникадәр сәер тоела. Ничек уйлыйсыз, ни өчен ул бездә уртачадан түбән дәрәҗәдә?

Динара ЗИННӘТОВА:
– IT өлкәсен карасак, анда бөтенләй башка төрле, без сөйләшә торган темалардан ерак булган кешеләр эшли. Бәлки менә шундый структураларны булдырган чакта хөкүмәт милли сорауларны алга сөрүче кадрлар турында уйларга тиештер. Коллективта бер генә шундый кеше булса да, тел мәсьәләсе бөтенләй игътибарсыз калмаячак. Әмма ул гади белгеч түгел, җитди вазыйфада булырга тиеш.

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Бу мәсьәләдә тагын бер гап-гади фактор бар – финанс мәсьәләсе. Әйтик, IT белгеч татар телендә проект ясый икән, ул я бөтенләй бер тиен акча алмый, я 20–30 мең сум хезмәт хакы ала. Әгәр ул шушы ук эшне рус яки инглиз телендә эшли икән, 200, 300, 500, 600 мең сум эшләргә мөмкин. Монда финанс аермасы берничә тапкыр дип түгел, нульләр саны белән исәпләнә.

:: Кызганыч, без милли контентны тарату мөмкинлекләре буенча да чикләнгән. Әйтик, Яндекс кебек зур компанияләр милли телләргә һәм милли контентка карата нинди мөнәсәбәттә?

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Монда ике аспект бар. Беренчедән, зур ширкәтләр һәрвакыт акча артыннан чаба. Әлбәттә, татарлар аудитория ягыннан аз түгел. Ләкин без шул ук контентны рус телендә чыгарабыз икән, аны татар, рус, чуаш, башкорт һәм башкалар да аңлый. Шуңа да мондый компанияләр өчен милли телләр беркайчан да фокус теле була алмый. Әйткәнемчә, аларга табыш кирәк. Теге яисә бу милләт акча китерә башласа гына борылып карый. Әмма тагын бер мөһим аспект – медиа һәм пиар мәсьәләсе бар. Әйтик, хәзер Яндекс Казахстанга чыгарга җыена. Димәк, казах теленә игътибар артачак. Әмма бу Яндекс өчен акча эшләү ягыннан түгел, пиар ягыннан әһәмиятле. Ягъни мондый зур ширкәтләр өчен милли телләр пиар, медиа яки башка төрле файда алу өчен кирәк. Шуңа да безгә милләт буларак күбрәк үзебезгә таянырга иде. Без, энтузиастлар – телмилләт тарафдарлары һәм дәүләт халыкның ихтыяҗын үстерергә тиеш.

Динара ЗИННӘТОВА:
– Бәлки, безгә төбәк телләрен өйрәнергә ярдәм итә торган масштаблы платформа, проект булдырып, аны шундый зур ширкәтләрнең берсенә, әйтик, «ВКонтакте»га тәкъдим итәргәдер? Бу эшнең бөтен Россия төбәкләре өчен файдалы булуын ассызыклап эшләсәк, IT гигантлар аның белән кызыксыныр иде, миңа калса.

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Бик яхшы идея. Һәм аны тормышка ашыру да – бик мөмкин эш. Моның өчен бу идеяне кирәкле кешегә «сатарга» гына кирәк.

:: Татарча интернет үсеп китсен өчен, бүген нинди этәргеч кирәк? Бу җәһәттән нәрсә таяну ноктасы була ала?

Райнур ХӘСӘНОВ:
– Кирәкле кешеләрне таныштыру, очраштыру.

Сәйдәш МИФТАХОВ:
– Ә иң мөһиме – бергә эшләтү.

Динара ЗИННӘТОВА:
– Амбассадорлар.

Ринат СӘФӘРОВ:
– Безнең төп проблемабыз кешеләргә, аларны үстерү, тәрбияләүгә, булганнарын бер-берсе белән таныштыруга кайтып кала.

Кадрия ФӘТХУЛЛОВА:
– Сәйдәш һәм Райнур кебек кешеләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

ХАЛЫК АВАЗЫ

15 мартта сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Ләйсан САФИНА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Баганада ут кайчан янар?

Балык Бистәсендә Октябрьнең 60 еллыгы урамында яшим. Техникум тирәсендә ике-өч ел элек бик матур итеп парк ясадылар. Без, өлкәннәр, шунда йөрергә чыгабыз. Тик баганаларда ут янмый. Кайчан кабызырлар икән?

Галия ГАЛИЕВА, 84 яшь

Марс Мәгыйзов, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы бистәнең башкарма комитеты җитәкчесе:
– Бу проблеманы беләбез. Утның янып-сүнеп алу гадәте бар. Моның буенча ГИСУга да, подрядчы оешмага да март аенда гариза җибәрдек. Белгечләр аны гарантия буенча килеп төзәтергә тиеш. Әлегә көтәбез. Утлар куйгач, тагын бер кат сезгә хәбәр итәрбез.

Авыруны нигә ярдыралар?

Әтнә районында 70 яшьлек энемне күмеп кайттык. Аның эчәклегендә яман шеш иде. Диагнозы билгеле, күп тапкыр операция кичерсә дә, табиблар ярдырырга кушты. Кабер казылган иде. Моргтан биргәннәрен көтеп, энебезне кич җиткәндә генә күмдек. Авыруы билгеле булгач, нигә шулай йөртергә? Миңа – 78 яшь. Елга бер мәртәбә диспансеризация үтәм. Үлгәч, безне дә шулай йөртерләр микән?

Фәһимә САБИРОВА. Казан

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте:
– Мәетне яру мәсьәләсе 2011 елның 21 ноябрендәге «Россия гражданнарының сәламәтлеген саклау нигезләре турында»гы 323 нче федераль канун нигезендә расланган. Анда медицина хезмәткәренең мәетне кайсы очракта ярырга җибәрү яки җибәрмәве билгеләнгән. Әлеге канунның 67 нче маддәсендә дини карашларга нигезләнеп, ире яки хатынының туганнарының, яисә законлы вәкиленең язмача гаризасы булган очракта, яки инде мәрхүм үзе исән чакта бу хакта теләк белдерсә, мәетне ярмау мөмкинлеге турында әйтелгән. Шул ук вакытта мәетне яру мәҗбүри булган очраклар да бар.

Редакциядән. Мәетне ярдыру яшькә бәйле түгел. Өлкәннәр даими диспансеризация үтсә, елга ике тапкыр хастаханәдә ятып чыкса, диспансер тикшеренүе узса, яру мәҗбүри түгел.

Бу хакта тулырак мәгълүматны газетабызның 16 февраль санында чыккан «Югалту ачысы» язмасыннан укып белә аласыз.

Пособие ник килми?

Узган елның ноябрь аена кадәр 7–18 яшькә кадәрге ике балага пособие алдым. Һәрберсенә 5800әр сум килде. Тик декабрьдән ул бетерелде, хәзер бер тиен дә килми. Район Пенсия фонды бүлекчәсендә: «Керемегез 100 сумга арткан», – диделәр. Ике бала тәрбиялибез, бер балабыз – авыру. Берсенә – 8, икенчесенә – 15 яшь. Ирем авыру кызыбызны карау өчен пенсиягә алдан чыкты. Мин үзем сәламәтлек буенча пенсия алам. Пенсиябез чыннан да 100 сумга гына арткан. Шуның өчен пособие бөтенләй тиеш түгелме?

Ләйсән МИНГАРИПОВА.
Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылы

Минзия Вәлиева, Социаль фондның Балык Бистәсе районындагы бүлеге җитәкчесе:
– Мингариповлар гаиләсендә җан башына уртача яшәү минимумы күләме тиешле 13 мең 135 сум 22 тиеннән артып киткән. Чынбарлыкта дөрес исәпләнгән. Законны беләсез, бер тиен артса да, пособие бирелми. Әмма шулай да, күңелен тынычландыру өчен, пенсия бүлекчәсенә барып, гаризасын кабат тапшырып карасын.

Сыерларга субсидия булырмы?

Кызым гаиләсе белән Алабуга шәһәренең Иске Алабуга дигән җирендә яши. Өч бала үстерәләр. Кызым авыру бала тәрбияли. Ике сыер тоталар. Ел саен субсидия бирелә иде. Ике ел инде бирмиләр, сәбәбе нәрсәдә икән?

РАЗИЯ апагыз. Алабуга

Александр Косов, Алабуга районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы:
– Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы малларга субсидия түләүгә гаризалар җыйганда, электрон кенәгәгә таяна. Авыллар буенча проблема юк. Кызганыч, Алабуга шәһәрендә мондый кенәгә алып барылмаган. Без әлеге системаны яңарттык. Быел Алабугада сыер тотучыларның барысы да субсидия алачак. Тик моңа кадәр алынмаган ике ел өчен түләнмәячәк.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

Рәхмәт ишетү рәхәт

Күзләрем начар күрә башлаган иде. Казандагы Бутлеров урамындагы хастаханәдә ятып чыктым. Операцияне тәҗрибәле табиб Рамил Гыймранов башкарды. «Хәзер күзлексез укыячаксыз, апа», – диде ул. Шулай булып чыкты да. Рәхәтләнеп Коръән укыйм хәзер. Табибыма дога укып, рәхмәтләр әйтәм, сәламәтлек, озын гомер телим.

Кәримә ҖӘЛӘЛИЕВА. Арча районының Кенәр авылы

ИЛСӨЯР ИКСАНОВА:

«АВЫР ЗАМАНДА УКУЧЫ ӘДӘБИЯТТАН ЯКТЫЛЫК ЭЗЛИ»

Заманча әдәбият нинди ул? Татар язучысын ниләр борчый? Иҗат хатын-кыз язмышына ничек тәэсир итә? Болар һәм башка мәсьәләләр хакында шагыйрә, Татарстан Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары Илсөяр ИКСАНОВА белән сөйләштек.

:: Шигырь кайчан языла, Илсөяр апа?

– Шигърияткә яшьлек хас. Теләсә кайсы шагыйрьнең беренче китапларын алып карасаң, Мөдәррис Әгъләм булсынмы ул, Зөлфәт, Ләис Зөлкарнәй, Ркаил Зәйдулламы – беренче шигырь китаплары ихлас хисләр, мәхәббәт белән сугарылган. Алар укучыны шушы ихласлыгы белән җәлеп иткән һәм әдәбиятка шагыйрь килә дип аваз салган фал булган. Ул вакытта әле автор – бик максималист: Разил Вәлиевнең: «Я дөньяны үзгәртәм мин бүген, я булмаса үзем үзгәрәм», – дигән сүзләрен генә искә төшерик. Алар әнә шул ихласлыгы, дөньяны үзгәртә алам дип уйлый алуы белән кадерле дә инде. Бу – хис шигърияте. Аннан соң инде шагыйрьнең күңеле сабыйлыкта калса да, тормыш тәҗрибәсе иҗатны икенчерәк юлга алып кереп китә. Халык язмышы, киләчәк, үткәннәр турында уйлану белән сугарылган саллы шигырьләр туа. Һәр язучының әнә шундый үсеше була. Дөрес, көчле дулкын булып килеп кереп, шул тигезлектә калган шагыйрьләр дә бар. Шагыйрь, бигрәк тә татар шагыйре – үз халкының язмышы, милләт язмышы белән яши торган шәхес, шушы гамьнәр юк икән, үсеш булмый. Мәхәббәт шигъриятендә генә калып, яңа биекләргә чыгу шактый катлаулы.

> Безнең эталон – Тукай. Ул 26 яшендә күңеле белән, бәлкем, язмыш тәҗрибәсе беләндер, үзенең олпат дәрәҗәсенә җиткән. Аның шигъриятенең үзәге – халык язмышы, халык җаны.

:: Соңгы вакытта нинди шигырьләр языла?

– Авыр шигырьләр языла. Бу бүгенге вазгыятькә, күңел халәтенә, күкләргә дә бәйледер. Ул бит, шигырь языйм әле, дип кенә шигырь тумый. Кирәк өчен язарга була, әлбәттә, ләкин ул чын шигърият булмый. Мин көчәнеп шигырь язмыйм. Ул килә икән, килә инде. Бүгенге халәтем нинди – шигырьләр дә шундый. Шуңа күрә соңгы вакытта язылган шигырьләрне матбугатка да чыгарасы килми хәтта. Авыр заманда халык әдәбияттан яктылык көтә, яктылык эзли.

:: Хатын-кызга иҗат ничек бирелә? Нәрсәләрдәндер баш тартырга туры киләме?

– Иҗат – син сайлап алган язмыш түгел, ул сине үзе сайлап алган. Әгәр дә ул күкләр тарафыннан йөкләнмәгән булса, мин шагыйрь яки язучы булам дип кенә язучы булып булмый. Иҗат ул – йөк. Һәм син үзеңне шагыйрь дип саныйсың икән, ул йөгеңне, миссияңне гомер буе алып барырга тиеш. Проза физик хезмәт кебек, күп вакыт һәм көч таләп итә. Шигырь исә күңел тынычсызлыгыннан, гамьнән туа. Ул гамь сине шәхси дөньяңнан аера. Хатын-кыз буларак, өеңне җыештырып, ашарга пешереп, шуннан канәгать булып дөнья көтү, бәлкем, җиңелрәктер. Әмма язучы гадәти тормыш ритмы белән генә яшәми, аның йөрәген бу дөньяда барган вакыйгалар, ил-көн язмышы телә. Туган җиренә, милләтенә карата гаделсезлек тойсаң да төн йокыларың кача. Дөньяда кылынган гаделсезлекләр дә борчый. Язучы ул – гуманист. Шуңа кулына каләм алган кеше гаделсезлекләрне тыныч күңел белән кабул итә алмый. Бүген иң авырткан җиребез – туган телебезнең язмышы. Инде бит авылларда да татар балалары русча аралаша, бу бик әрнетә. Ә кемнәрдер, бу миңа кагылмый, дип яши бирә...

:: Язучылык һөнәр булып саналган көнгә кайчан да булса җитәчәкбезме?

– Кеше һәрвакыт идеаль җәмгыять турында хыяллана. Аңа барып җитә алырбызмы, юкмы – анысы икенче мәсьәлә. Кара акыл белән исәпләгәндә, андый мөмкинлек булырга тиеш кебек. Элек тә бит фәкать иҗат белән генә шөгыльләнгән профессиональ язучылар булган. Бу – дәүләтнең язучыга мөнәсәбәтеннән тора. Язучылар берлегендә 300 язучы исәпләнә икән, аларның барысы да профессионал булырга тиеш, дигән сүз түгел. Булса, бер дистә тирәсе булыр инде ул. Хөкүмәтнең шулкадәр генә язучыны тотарга мөмкинлеге бар, дип уйлыйм. Ә әдәбиятта һәрбер язучының – үз урыны. Наив әдәбияттан алып, югары элитар әдәбиятка кадәр мәйданның бөтен баскычлары да тулы булырга тиеш. Шулай булмаганда зур әдәбият була алмый. Бездә бит берлектә тормаган каләм тибрәтүчеләр күп. «Акылыннан яза-яза, бөтен кеше шигырь яза», – дип әйтсәләр дә, халкыбызның күңеле шигърият белән тулы икән, бу – бик уңай күренеш.

:: Сез зур багажлы, матбугат өлкәсен генә алсак та, «Сөембикә»ле, «Түгәрәк уен»лы юл үткәнсез. Үткәннәргә карап, хәзер инде мин болай эшләмәс идем, дигән уй туганы бармы?

– Хәзерге тәҗрибәмнән чыгып, болай эшләмәс идем, дигән уй туганы бар, ләкин тормышымдагы ул этапларның барысы да кирәк булган, дип уйлыйм. Аларның һәрберсе баеткан, тәҗрибә биргән, ахыр чиктә шулай язган булган.

Әдәбиятка бик яшьли килеп кердем. Ул чакта «Яшь ленинчы» газетасында хәбәрче булып эшләгән шагыйрь Нияз Акмал, мине Лаеш районы Татар Сараланы авылы мәктәбендә эзләп табып, иҗат канатлары куйды. Шул очрашудан соң без аралашып тордык. 8 нче сыйныфларда укыганда «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә килгәләп йөри башладым һәм Зөлфәт абый, Мөдәррис Әгъләм, Госман Садәләр белән таныштым. Аларның аурасын тою гына да нык тәэсир итә иде. Аннан университетта укыган еллар, бер генә ел булса да нәшриятта эшләп алу, Фәрваз абый Миңнуллин, Рәис абый Даутов белән дуслашу офыкларымны киңәйтте. Сер түгел, без күбебез тарихыбызны мәктәп дәреслекләрендә язылган кысаларда гына белеп үстек. Дөрес, әтием аша (ул КФУның тарих факультетын тәмамлаган) мин татар тарихының дәреслекләрдән түгәрәк булуын беркадәр аңлый идем, чөнки әтиемнең университетта бергә укыган дуслары, өебезгә килеп йөргән кайбер язучылар белән аңгәмәләре минем колакка да керми калмады. Университетта Татарстан тарихын безгә Рафаэль Шәехов укытты, үз тарихыбызга күзебезне ачкан мөгаллимебез булды ул.

Роберт Миңнуллин, «Яшь ленинчы» газетасына эшкә чакырып, балачак хыялымны тормышка ашырды. Әмма дөнья бит гел үзгәреп торучан. Туксанынчы еллар җитте, «Шәһри Казан» газетасы ачылды. Ул бик кыю, заман сулышы белән өртелгән басма буларак мәйданга чыкты. Бу – рухи күтәренкелек чоры, мин ул вакытларны бик сагынам.

«Салават күпере», «Сөембикә» журналларында эшләгән вакытларны да сагынып искә алам. «Сөембикә» чоры гаҗәеп кызыклы шәхесләр белән очраштырды, күп юллар үтәргә, дөнья күрергә мөмкинлек бирде. «Түгәрәк уен» басмасы журналистлык эшчәнлегемнең кульминациясе булгандыр, мөгаен. Моңа кадәр татар фольклор журналы булмаган, ул беренче шундый басма иде. Халкыбызның гаҗәеп бай рухи хәзинәсенең бер тамчысын гына булса да укучыга җиткерә алуыбыз белән бәхетле идек без. Дистә елга да тулмаган кыска гына арада да никадәр яңа мәгълүматлар табарга, Себер якларында йөрергә, архивларда казынып, моңа кадәр билгеле булмаган фактларны ачыкларга насыйп булды. Милләтебез өчен файдалы эшләр эшли алдык, дип уйлыйм. «Түгәрәк уен» журналының ул чорын хәзер дә сагынып искә алалар, җылы сүзләр ишетү шундый рәхәт.

:: Соңгы вакытта сез гел юлда, очрашуларда. Нәрсәләргә сөенеп, нәрсәләргә көенеп кайтасыз?

– Кая гына барсак та, йөрәкне иң әрнеткәне – туган тел мәсьәләсе. Мәктәпләрдә балалар үзара рус телендә аралаша, хәт-

та әби-бабай да оныгы белән туган телендә сөйләшми. Аның сәбәпләре дә аңлашыла инде. Прагматик яшьләр һәр гамәлгә рациональ якын килә, ягъни кирәкме бу миңа тормышта, юкмы. Кулланыш даирәсе кими барган татар телен белү алар өчен мөһим түгел кебек. Әмма бу – ялгыш фикер. Татар теле – төрки телләрнең нигезе. Дөньядагы 14 телне белсәң, бөтен телне өйрәнергә була, диләр. Татар теле – шул 14 телнең берсе. Чынлап та, татар телен яхшы белгән сурәттә, төрки халыклар белән бик җиңел аралаша алабыз. Ә төрки дөнья бик зур. Авазлар системасы ягыннан караганда да, чит телләрне өйрәнүдә файдасы зур. Шул ук дөньякүләм аралашу теле булган инглизчәне өйрәнгәндә генә дә безнең «һ», «ә», «ү» «җ»ләрнең бик кирәге чыга. Әмма туган телне өйрәнү ул практик җәһәттән генә була алмый.

> Туган тел – әби-бабаң, әти-әниеңнән калган әманәт. Әманәтне югалтырга ярамый, син аны киләчәккә алып барып тапшырырга бурычлы. Без беребез дә милләтебезне, әти-әнине сайлап тумыйбыз. Ул – Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры. Бу җәһәттән, дин юлында булган күп кенә кешеләребезнең туган телләрен санламавы мине сагайта.

:: Ә сөенечләр?

– Сөенечләр турында күп сөйләргә була, әлбәттә. Яшьләр күпкә белемлерәк, алар – бүгенге заман кешеләре генә түгел, киләчәк заман кешеләре дә. Бәлки, безгә аларны аңлап бетерү читенрәктер дә. Яшьләр китап укымый, дигән фикер белән дә килешеп бетмим, дөнья әдәбияты, бүгенге әдәбият белән таныш күп яшьләрне беләм. Әмма татар әдәбиятын бик тирән беләләр дип әйтеп булмый. Белемнәре, кызганыч, мәктәп программасы белән чикләнә. Телгә карата кызыксыну уяту, иҗатка дәртләндерү җәһәтеннән, Телләр комиссиясенең проектларын искә алып үтәргә мөмкин. Татар телендә язылган әдәби әсәрләр бәйгесе «Татарча язып та акча эшләп була. Татарча язып та танылырга була» дигән фикер тудыра. Хәзерге прагматик буынга тәэсир итүнең бер ысулы. «Татар сүзе» бәйгесе дә – шуның бер мисалы. Әмма бу проектлар дәвамлы, системалы булырга тиеш.

:: Заманча татар әдәбияты нинди ул?

– Нигездә, ул традицияләрне саклый. Без бөтенләй яңа татар әдәбияты тудырдык, дип әйтә алмыйм. Телебезнең сыгылмалылыгын, нечкәлеген югалта барабыз кебек. Төп аерма, мөгаен, кыскалыкка омтылудадыр. Бу – гомуми дөнья әдәбиятындагы процесс. Аннан, әйткәнемчә, яшьләр дөнья әдәбиятын укый, андагы образлар системасы, тенденцияләр тәэсир итми калмый. Чиста милли әдәбият кими бара. Әлбәттә әдәбият синтезда үсә, бу табигый процесс. Хәтта Азия халыкларыныкы, япон әдәбияты, әфган әдәбияты булсын (безгә килеп җиткән кадәресе), күбесе – Америкада яшәп иҗат иткән әдипләрнең әсәрләре. Алар инде чиста япон, әфган әдәбияты гына түгел. Мәсәлән, Харуки Мураками әсәрләре Кобэ Абэныкыннан бик нык аерыла. Шул ук хәл төрек әдәбиятында да сизелә. Әдәбият шундый синтездан башка үсә дә алмыйдыр. Безнең әдәбиятка килгәндә, яшьләрнең шигърияте үтә үзенчәлекле, кайвакыт сагайтып та куя. Әдәбиятның какшамас кануннары бар. Аңа ябышып ятарга димим, әмма кулына каләм алган кеше әдәбиятның нигезен белергә тиеш. Чөнки яңадан велосипед уйлап табып булмый. Аны камилләштерергә була. Ә бездә яңадан велосипед уйлап табарга теләүчеләр дә очрый.

Шигърияттә метафора белән мавыгу көчле. Өсте-өстенә өелгән метафоралар белән табышмак-шигырь язалар. Шигырь табышмак түгел, укучы аны ребус шикелле чишеп утырмый. Шигырь төгәл ритмикасы, аһәңе, фикере белән җанга һәм аңга кагыла икән, укучы аны кабул итә. Бу – минем фикерем, бәлки, бу яңа буынны (альфа буын диләрме инде хәзер) без аңлап җиткермибездер.

:: Хатын-кыз – ничек кенә булмасын, барыбер нечкә күңелле зат инде ул. Бигрәк тә иҗат кешесе. Җитәкчегә исә авыр сүзен дә, нахагын да, урынлы-урынсыз тәнкыйтен дә күтәрергә туры киләдер. Авыр сүзне ничек үткәрәсез?

– Үземне күбрәк иҗат кешесе дип саныйм. Әмма вазыйфага алынгансың икән, аны тиешенчә башкарырга кирәк. Һәр эшнең дә үз нечкәлекләре була. Оештыру эшләре, планнар, отчетлар... Монда инде үз асылыңны онытып торырга туры килә. Кешеләр белән эшләү бигрәк тә катлаулы, аеруча иҗат кешеләре белән. Чөнки алар һәрберсе – үзенчәлекле дөньялы, нечкә күңелле кешеләр. Иң курыкканым – кеше күңелен яралау.

...Язучылар берлегенә керергә теләүчеләр күп. Әмма арада бик йомшак, хәтта өйрәнчек дәрәҗәдәге әсәрләр белән килүчеләр бар. Алар үз иҗатларын бәяли алмый, тәнкыйтьне дә авыр кабул итә. Монда инде кешенең күңелен дә төшермәскә, әдәбиятка да зыян китермәскә кирәк. Мин кайвакыт кешеләрнең берлеккә керергә атлыгып торуын аңлап та бетермим. Язучылар берлегенә керергә килгән кеше, миңа калса, үзендә язучылык йөген тоярга тиеш. Күбесе бит, уртакул язучыларны мисал итеп: «Мин дә «аның» хәтле генә язам, мин дә берлектә торырга тиеш», – дип килә.

Әдәби премияләр, әдәби конкурслар тирәсендә бәхәсләр табигый. Премиягә, бәйгеләрдә җиңүгә дәгъва кылган кеше, әлбәттә, бик шәп әсәр иҗат иттем дип ышана. Алай булмаса, аның дәгъвасы да булмас иде. Әмма башкаларның иҗатын да күрә белергә кирәк.

Нахак сүзләр дигәндә, бу урында, калын тиреле булырга тырышам, әмма барыбер дә без – йөрәк белән яши торган кешеләр. Шәхсән миңа түгел, берлеккә кагылышлы нахак сүзләр дә яралый. Андый чакларда халык акылына таянам, безнең халыкның бик күп зирәк мәкаль-әйтемнәре бар бит. «Ашаган белми, тураган белә», – дисең дә...

:: Хатын-кызларга нинди теләгегез бар?

– Тән һәм җан сәламәтлеге, һәр хатын-кызның бу тормышта терәге булуын телим. Терәксез яшәү авыр. Ул шулай яратылган: хатын-кыз көчле ир-ат ышыгында яшәргә тиеш. Әгәр дә бу ышык юк икән, ул җилгә каршы үзе чыгып баса һәм беркадәр хатын-кыз сыйфатларын да югалта. Беркемгә дә мондый язмыш бирмәсен, кадерле булып, терәк тоеп яшәсен хатын-кыз. Әлбәттә, Такташча әйткәндә, хатын-кызның бөтен матурлыгы – ана булуда. Бу – табигатьтән бирелгән миссия дә, бәхет тә. Аналарга бала игелеген күреп яшәргә язсын!

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ИЛФАК ШИҺАПОВ (ТОРМЫШ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ)

АВЫЛ НИ ӨЧЕН КӨЛӘ?

Соңгы елларда авылларыбызның бәгырьләре телгәләнсә дә, аларның элеккедән килгән бер матур гадәтләре сакланып калды – монда вак-төяктән дә кызык таба һәм шул кызыктан үзләре үк рәхәтләнеп көлә беләләр. Кайвакыт карыйсың – юк кына нәрсә кебек, ә ул инде озак елларга бара торган авыл фольклорына әйләнгән. Тагын шунысы да бар: бер авыл кешесе икенче авыл шаяртуларын, мәзәкләрен аңламаска да мөмкин.

...Авыл кибете. Берсе керә, берсе чыга. Кибеткә килүчеләр арасында конкрет әйбер алырга дип түгел, элеккеге гадәт буенча, берәр яхшы әйбер кайтмаган микән, дип килүчеләр дә бар. Болары – гадәттә, пенсионер карчыклар. Беркөнне алар шулай гадәт буенча кибеткә җыйналалар. Ә кибет универсаль, ягъни монда ипи дә, башка азык-төлек тә, кием-салым да, хуҗалык товарлары да саталар.

Йөриләр шулай карчыклар акрын гына кибет буйлап, тегене-моны карыйлар, юк-бар сөйләшәләр. Шулчак кибеткә шаярырга ярата торган бер авыл ире килеп керә. Керә, бер яртыны ала һәм, инде чыгып китеп барганда, кинәт пыяла витриналарның берсе янында туктап кала. «Кара әле, – ди ул үзалдына, – кайткан бит, ниһаять, кайткан». Кибетче хатын моның нәрсә күргәнен дә, шаярганын да аңлый. «Кайтты шул, – ди ул да, уенга кушылып. – Кыйммәт тә түгел, сыйфаты да яхшы, диләр. Аласыңмы әллә?»

Әбиләр, бу әңгәмәгә игътибар бирмәгән булып кылансалар да, чынлыкта дикъкать белән тыңлыйлар.

«Юк әле, – ди теге ир. – Миңа килешеп бетмәс, хәзер хатынны җибәрәм. Бетә башласа, калдыр әле бер дүрт-бишне». Кибетче ризалаша. Ир кабаланып чыгып китә. Әбиләр әлеге ир караган витринага килеп сылана. Иң мөһиме, берсе дә: «Нәрсә күрде ул?» – дип сорамый, күзләре белән пыяла астын актара. Ә анда чәч каптыргыч, банка капкачы ише вак-төяк кенә. Озак күзлиләр әбиләр витринаны. Аптырагач, берсе – кибетче безгә юри яхшы әйбер бирми дип уйлап яшәүчесе – кибетче янына килеп баса да кулъяулык төененнән йөз тәңкә акча чыгарып, калтыранган куллары белән кибетчегә суза: «Кызым, теге... ни... Ильяс сораган нәрсәне миңа да икене генә бир әле». Кибетче, елмаймыйча, әбинең акчасын ала, аңа ялтыравык кәгазьгә төрелгән ике презерватив чыгарып сала. Карчык, аны-моны әйтми генә, алган товары белән сдачасын кесәсенә тыгып куя да: «И-и, ипи апарасы куйган идем, оныта язганмын», – дип, өенә ашыга. Иптәшләре артыннан кырын күз белән генә күзәткән өч-дүрт карчык та «начар әйбер булса, ул алмас иде» дигәнрәк фәлсәфә белән, чиратлап килеп, ни икәнен үзләре дә белмәгән «нәстә»не алалар да өйләренә таралышалар. Өйгә кайткач, теге «нәстә»нең ни икәне ачыклана (кайсының – малае-кызы, кайсының оныгы бар), билгеле, әмма инде соң була.

Авыл өч көн көлә. Карчыклар берәр атна кибет тирәсендә күренми. Авылга берәр айга рәхәтләнеп сөйләргә яңа мәзәк әзер.

Ләкин ни булса да, бу көлү эчкерсез, болай гына, кызык өчен генә...

...Шул ук авыл урамы. 92 яшьлек Сабира карчык капка төбендә аякларын угалап, уфылдап утыра. Көтү кайтыр вакыт – халык берән-сәрән шул якка малларын каршыларга атлый. Үтеп баручы бер авыл хатыны Сабира карчыктан хәлләрен сораша. «И-и, – ди тегесе, – 92гә җиткәч, хәл ничек булсын инде?! Менә аякларым сызлауга түзә алмыйча утырам әле».

Сүзгә бу әңгәмәне ишетеп-тыңлап торган, үзе, чыннан да, аяклары авыртудан интеккән күрше хатыны кушыла. «Кара син аны, – ди ул, зәһәрләнеп. – Бүген генә ике тапкыр кибеткә төшеп мендең – үзе дүрт чакрым, сигез тапкыр тирә-күршеләргә кердең. Юри санап утырдым. Соң, мин шуның кадәр йөргән булсам, хәзер үлгән була идем бит инде...»

Авыл тагын көлә. Шул арада «Сабира карчык кадәр йөрдем» дигән гыйбарә халык сүзе арасында үз урынын алып та өлгерә.

Үзебезнең авылга кайтканда да, чит авылларга баргач та, өлкәнрәк, шаянрак кеше белән сөйләшергә туры килгәндә, мин сүзне шундый авыл мәзәкләренә корырга тырышам. Әллә нәрсәләр ишетергә туры килә. Кайберләрен аңлау өчен, чыннан да, шул авылда яшәргә, мәзәктә катнашкан кешеләрне белергә кирәк. Ләкин кайберләре бар кешегә дә аңлашыла.

Менә, әйтик, Аксубай районы Яңа Үзи авылында кайчандыр булган бер хәл. Ике күршенең үтереп башлары авырта. Кичтән яхшы гына салынган, баш төзәтергә акча юк. Дөресрәге, хатыннар акча бирми. Нишләргә? Берсе сорый: «Әзи, синең хатынга бодай кирәкмиме?» «Кирәк», – ди тегесе, бераз уйлап торгач. «Минекенә дә кирәк кирәген, ну келәттә бер-ике капчык бар әле». Уйлашалар да болар, берсенең келәтеннән бер капчык бодайны алып, икенчесенә керәләр. Ир өйгә керә. «Хатын, син кирәк дигәч, бодай алган идем дә...» Нишләсен, товар булгач, бирә инде хатын бер яртыны. «Келәткә кертеп куегыз», – ди дә үзе эшкә китә. Ике күрше, теге яртыны бөкләгәч, капчыкны күтәреп, бодайны алып чыккан йортка кереп китәләр. Монда да шул ук хәл. «Хатын, бодай алган идем...» Тагын бер ярты. И всё! Баш төзәлгән, дөнья рәхәт, бодай да үз урынында. Мондый мәзәк хәлләрне авыл саен ишетергә була. Тыңлый гына белергә кирәк. Ләкин эш анда түгел. Эш шунда: бүгенгә әле авыл көлә белә. Кеше, ни дисәң дә, үзенә нык авыр булганда да, каты авырганда да көлә ала. Үләргә яткан кеше генә көлә алмый. Ә бүген безнең авыллар һаман аз-азлап көлә икән, димәк, алар, бик нык авырып китсәләр дә, әле үләргә ятмыйлар. Шунысы иң мөһиме инде аның...

(«Кеше эзлим...» китабыннан)

Сайдашев
Шәйхразыев
Гений!
Теләк
Аңа, абый диләр, шунысы күңелсез

Аллаһныкы
Кечкенә кеше
ВАЗ-2121
Балавыз сыгу
... дә син бар
...-сәлим
ТР районы
Тимергалиева
Хәмитова
...-кул
Танылган физик
Лавров министрлыгы
Ятим
Такси фирмасы
...мыни соң йөрәк?
Йә булмаса
Актер ... Касыймов
Ежов званиесе
Булмас хәл
Япон вирусы
«Тойота» төре
Әләме бар
Танып ...
Илә
Мөһимлек
Бенин шәһәре
Кеч
Уфа мэры
Гавана иле
... 12 кыз идек
Табанаков
Атнада җиде
ЗАГСка икенче тапкыр бару
Олимпиада-1988 хуҗасы
Сиртмә кое кучтәнәче
Порт тросы
Казан зираты
Кремль журналистлары
Шарык халыклары бәйрәме
Гиперссылка
Композитор Чуганаев
Мал-...
Бир киресе
Кыска түгел
Кушанашвили
Казан бистәсе
Лаеш авылы
Алмашлык
Джулия ...
Кәбисә
Чуаш елгасы

...-том
Ризык
Җәрәхәт
Урманда «утрау»
Усал
Пятачок бүләге
Яу кычкыруы
Очкыч
Укучы яза
Биокыр
Ганс Христиан
Ректор Рубин ...

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Фәтхетдинов, Салих, һәвәс, илаһи, әл, кием, Хәмдүнә, Лилия, картая, Камри, Дусил, утопия, ил, белән, Зу, Куба, без, аерылу, су, ваер, Курган, Сеул, мөлкәт, Алтан, Сәүбән, Ормонд, Ута, им, ит, ярa, шар, Алсу, аура, Абдуллин, Андерсен.

Вертикаль: Фәйзрахманов, сылтама, МИД, белү, Убер, үксез, мә, Наил, көн, даһи, кәрлә, ул, инша, Әлки, нарком, алан, Нива, елау, егәр, ярсу, әһәмият, Ратмир, ура, Васил, озын, Отар, Ан, пул, яки, Усад, аяк, ел, Ом, Усуту, Булат, Хәйруллина, Нардуган.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Прайд ул нинди җәнлекләр төркеме?
а) арысланнар;
б) филләр;
в) юлбарыслар.

2 Microsoft компаниясенә кем нигез салган?
а) Стив Джобс;
б) Билл Гейтс;
в) Илон Маск.

3 Котлы Бөкәш авылы элек кайсы районның үзәге булган?
а) Кызыл Чишмә районы;
б) Кызыл Байрак районы;
в) Кызыл Йолдыз районы.

4 Бетховен көйләр яхшырак язылсын өчен нишләгән?
а) тәүлегенә 3 сәгать йоклаган;
б) башына салкын су сипкән;
в) көй язасы көнне ашамаган.

Җаваплар: 1-а); 2-б); 3-в); 4-б).

Әз-мәз мәзәк

Интернет булмаганда безнең әти-әниләр вакытларын ничек үткәрде икән? 18 абый-сеңлемнән сорадым, берсе дә әйтә алмады.

***

Экономияле уенчы, «Поле чудес»ка икенче тапкыр килеп, буш банкаларын алып киткән.

***

– Официант, без ит, лактоза, глютен һәм шикәр ашамыйбыз. Нәрсәгә заказ бирик икән?
– Таксига.

***

Кичәге кластерга коуч килде. Аның кейсларын карап, мастермайнд уздык.

***

– Сәлам! Мин хатын эзлим.
– Күрмәдем.

***

Шиномонтаждан смс:
– Хөрмәтле клиент! Әгәр сез һаман да исән булсагыз, җайлап кына юл кырыена туктагыз әле, тәгәрмәчләрегезне борып куярга оныткамбыз.

***

– Минем песи ни өчендер урамдагы чыпчыкларга һөҗүм итә, ә өйдәге тутый кошка тими.
– Кара көнгә саклыйдыр.

***

– Ни өчен сез бу вокзалны шәһәрдән еракта төзедегез?
– Башта шәһәргә якынрак төземәкче идек, аннары тимер юлга якынрак төзергә булдык.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758. Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 227

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+